«Бәхетле көннәрем алда әле»

Самат – ялгызы гына гомер кичерүче II группа инвалид. Җәй көне шәһәр һавасы аеруча да авыр, ди ул. Шуңа күрә дә ул авылда җәй айларында үз гаиләсенә сыендырырга риза булган мәрхәмәтле гаилә яки берәр кеше белән танышырга өметләнә.

6 БИТ

Фарсель Зыятдинов:

«Тын алырга да вакыт юк»

Бакчачы да ул, агроном, педагог, икътисадчы, галим, язучы, шагыйрь, журналист, тәрҗемәче, геодезист, топограф та. «Бу өлкәләрнең барысы да күңелемә бертигез якын», – ди бүген – 1 июньда, 80 яшьлек юбилеен каршылаучы Фарсель абый Зыятдинов.

12 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Пәнҗешәмбе | 1.06.2017 | № 58 (5820)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

ҮЗАРА САЛЫМ: КАНӘГАТЬСЕЗЛӘРГӘ ҖАВАП

Үзара салым акчасы турында һәр җирлекнең генә түгел, һәр гаиләнең үз фикере бар дисәм дә, ялгыш булмас. Бирәүләр хуплый, икенчеләре, бар нәрсәне халык өстенә калдыралар дип, ризасызлык белдерә. Кайдадыр халыктан 150-200 сум акчаны көчкә җыялар, ә менә Әтнә районының Түбән Бәрәскә авыл җирлегендә яшәүчеләр өченче ел рәттән үзара салым акчасын гаиләдәге һәр кешегә 1000 сум исәбеннән җыйганнар! Бер карасаң, аз акча түгел. 200 сум акча бирмәскә җан тартышып торган кешеләрне белгәннән һәм күргәннән соң, гаҗәпләнү бермә-бер арта.

Зөлфия Хәлиуллина фотосы

7 БИТ



БӘХИЛЛӘШҮ

4 БИТ

КИҢӘШ САНДЫГЫ

9 БИТ

РЕСПУБЛИКАДА

ӘЛКИ

Әлки районының Апак авылында традицион «Шомырт чәчәге» бәйрәме узган. Соңгы елларда әлеге чара авылда берникадәр югалып торган булган, әмма туган җир дип җан аткан, тынгысыз апаклылар моны кабат терелтеп җибәргән.

АЗНАКАЙ

Азнакай шәһәре базары директоры Дамир Игътисамов хәбәр иткәнчә, биредә ике ел эчендә аренда бәяләре ике тапкырга (20 процентка) киметелгән. Шулай ук өлкән яшьтәгеләр, пенсионерларга үз хуҗалыкларыннан артып калган азык-төлекне сату өчен бушлай сәүдә урыннары да бирелгән.

ЧАЛЛЫ

29 майдан башлап, Чаллыда шәһәр транспортында йөргән өчен билет бәяләре арткан. Җәмәгать автобусында булсынмы, трамвайда барган өчемме, хәзер 22 сум түләргә туры килә. Шәхси эшмәкәрләр хуҗа булган кече автобусларда да бәя шулай ук. Бу форсатны таксистлар да кулдан ычкындырмаган: бәяне алар да күтәргән.

ӘЛМӘТ

Әлмәт шәһәрендә алтынчы кат тәрәзәсеннән егылып төшеп, дүрт яшьлек кыз бала үлгән. Фаҗига 30 май иртәсендә булган. Егылып төшкән кыз баланы шунда ук «Татнефть»нең медик-санитар частена озатканнар. Әмма җәрәхәтләре нык булу сәбәпле, сабыйның гомере операция өстәлендә өзелгән.

ӘТНӘ

Инглиз телендә узган республика фестиваль-конкурсында Олы Әтнә мәктәбе театр коллективы беренче урын яулаган. Әлеге бәйге Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгының эш планы нигезендә, English First компаниясе башлангычында уздырылган.

КУКМАРА

Халыкара балаларны яклау көне уңаеннан, Кукмара районы прокуратурасы уздырган мәктәпкәчә яшьтәге балалар һәм мәктәп укучылары арасында «Имин каникуллар» дигән иҗади конкурс җиңүчеләренә Мактау грамоталары, истәлек бүләкләре тапшырылган. Аларны район прокуроры Ришат Шакиров, мәгариф идарәсе җитәкчесе Роберт Мансуров тәбрикләгән.

Яңалыклар район газеталары сайтларыннан алынды

ФАТИРЫ БАР, АВТОБУСЫ ДА БУЛЫР

Казанның Оренбург трактында төзелеп килә торган 14нче микрорайоннан социаль ипотека программасы буенча фатир көтүчеләр шактый. Инде 2015 елдан бирле «өй туе» уздырырга хыялланган гаиләләргә, билгеле бер сәбәпләр аркасында, сабыр гына көтәргә туры килде. Ниһаять, сөенечле яңалык – 31 май көнне 14нче микрорайонда 2нче йорт кулланууга тапшырылды. Бу – микрорайонда төзелеп беткән өченче торак.

tatarstan.ru

Ел башыннан Татарстан Президенты каршындагы Дәүләт торак фондына караган программалар буенча 2994 фатирга исәпләнгән 66 йорт кулланууга тапшырылган. Аларның алтысы Казанда сафка баскан.

14нче микрорайон — социаль ипотека буенча торак салу белән шөгыльләнгән Казандагы зур проектларның берсе. Биредә барлыгы 3800 фатирга исәпләнгән 17 йорт төзергә җыеналар, ягъни ун меңнән артык кеше социаль ипотека программасы буенча фатирлы булачак дигән сүз. Анда биш балалар бакчасы, ике мәктәп, күп катлы парковкалар булдыру да каралган.

Әле күптән түгел генә 14нче микрорайонда 1нче йорт кулланууга тапшырылган иде. Ниһаять, 255 фатирга исәпләнгән 2нче йортта да «өй туй»лары гөрләячәк. Әлеге тантаналы чарада Татарстанның төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары Илшат Гыймаев, Дәүләт торак фондының торак булмаган фонд белән идарә итү һәм аны эксплуатацияләү идарәсе начальнигы Максим Корнянен да катнаштылар. Җитәкчеләр микрорайондагы 3-4нче йортлар җәй азагына кадәр төзелеп бетәр дип ниятли.

Юл булмау – микрорайоннан фатир алган кешеләрне борчыган мөһим мәсьәлә. Микрорайонга автобус җибәрүне сорап, алар Казан шәһәре мэриясенә дә хатлар юллаган булганнар. Әмма юлның артык тар, куркынычсызлык ягыннан ышанычсыз, асфальт катламы нык булмаганга, әлегә зур автобуслар җибәрелмәячәк. Сентябрьгә биредә юлларны киңәйтергә телиләр, шуннан соң автобус мәсьәләсе дә хәл ителер кебек. Әлегә бирегә микроавтобуслар гына йөри.

Шәһәр кәефе

ЯКУБ АКЪЕГЕТОВ,
пенсионер:

– Татарстанга килгәнемә – 50 ел, тумышым белән Пенза төбәгеннән. Казанда консерватория тәмамлагач, Буа районында эшләдем. Буада гаилә кордым, балалар үстердек. Гаиләдә һәрвакыт ана телебездә сөйләшәбез. Хатыным Рәмзия татар теле укытучысы да бит әле. Казанда исән-сау гына гомер кичерәбез, Аллага шөкер. Балаларыбызны татар теленә өйрәтеп үстерик. Күңелләренә хуш килгән музыка коралында уйный белсәләр, тагын да әйбәт.

ЛАНДЫШ БАБАНИЯЗОВА,
әдәби хезмәткәр:

– Казанда машиналар бигрәк күп, һава җитми. Туган авылым Урта Кирмәнгә кайткач, сулышлар иркенәеп китә. Чит илгә барырга исәп юк. Җәйге ялда авылга әтиәни янына кайтабыз, Алла боерса. Җиләк чорын көтәм. Мамадышта халык ел саен җиләк җыеп мәш килә. Җиләк сатып машина алучылар да бар. Машинага җитәрлек җыеп булмас булуын, шулай да җиләккә баруның үз тәме бар.

ДИНӘ ХИСАМЕТДИНОВА,
тележурналист:

– Казанның Авиатөзелеш районында туып-үстем. Шәһәр кызы булсам да, шау-шуны яратмыйм. Мин – гаилә кешесе, тынычлыкны яратам. Ходай балалар үстерергә насыйп итсен иде. Татар халкының милли ризыклары шулкадәр төрле: бәлеш, өчпочмак, гөбәдия, кыстыбый, чәк-чәк… Бу ризыкларны әзерләү – үзе бер бәйрәм. Эшемне бисмилла әйтеп башлыйм. Лондонга барып кайтырга хыялланам.

АЛЬСИНА ОДРЯЕВА,
хезмәткәр:

– Шәһәр үзәгендәге урамнардан көнләшәм: аларда ел саен төзекләндерү. Отары бистәсенә бара торган юлларны да яңартасы иде. Бистәләрдә яшәүчеләр дә Казан кешеләре булып санала лабаса. Спорт белән шөгыльләнәм. Төрле тукымалардан курчаклар ясыйм. Кешегә нинди булса да бер шөгыль кирәк ул. Казан читендә өй төзергә хыялланабыз. Әлмә кайларда, диңгез буйларындагы йорт кирәкми. Үзебезнең Казан кадерле.

ӘХТӘМ ГАТИЯТУЛЛИН,
токарь:

– Арчадан килеп, Казанда заводка урнашкан идем. Тимерчелек цехында 42 ел хезмәт куям инде. Аллага шөкер, бүген дә эшләп йөрим әле. Тимерчелек цехы дигәч тә, без тимерчеләр түгел. Төрле детальләр ясыйбыз. Шәһәр читендәге бакча кишәрлегендә кайнашырга яратабыз. Хатыным Зөлфия яшелчә үстерергә һәвәс. Май аенда туфракта биш градус салкын булды. Хатыным: «Быел яшелчәләр үстереп булмый, ахрысы», – дип борчыла.

Чыгарылыш сыйныф укучылары Бердәм дәүләт имтиханнарын тапшырып йөрсә дә, калган балалар өчен иң тәмле һәм рәхәт чаклар җитте. Ниһаять, аларның зарыгып көтеп алган җәйге каникуллары! Тугыз ай буе аерылмаган китап-дәфтәрләрне читкәрәк алып куеп, рәхәтләнеп ял итәргә, киләсе уку елына көч-куәт туплап калырга кирәк. Шәһәр балалары, гадәттә, йә авылга кайта, йә лагерьларда ял итә. Соңгылары өчен мәктәп яны лагерьлары үз эшләрен башлап та җибәрде инде. Алар биш көнлек эш режимында эшләячәк.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Ур-ра-а! Каникул!!!

Зөһрә САДЫЙКОВА

Мәгариф идарәсе башлыгы Илсур Һадиуллин хәбәр иткәнчә, Казан мәктәпләре укучылары өчен 27 июньгә кадәр 149 мәктәп яны лагере эшләячәк. Алар базасында 13 меңләп укучы ял итәр дип планлаштырыла. Моннан кала, мәктәп базаларында 14 яшьтән алып 18 яшькә кадәргә 1700 бала өчен хезмәт һәм ял отрядлары да эшләячәк. Ә гомумән Татарстан лагерьларында якынча 218 мең бала ял итәр дип көтелә.

– Балаларның ялы гадәттән тыш хәлләр аркасында бозылмасын өчен, ЮХИДИ идарәсе һәм Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы дәүләт учреждениесе белән берлектә, сулыкларда үз-үзеңне дөрес тоту буенча чаралар һәм "Игътибар – балалар!" акциясе узачак, – дип белдергән иде Илсур Һадиуллин.

Сүз уңаеннан, Казан Россия шәһәрләре арасында балалар белән җәйге сәяхәт өчен иң яхшы өчлеккә кергән. Әлеге топның шәһәр исемлегендә Мәскәү, Санкт-Петербург, Екатеринбург, Самара, Ярославль, Владимир, Калининград, Псков һәм Кострома да бар.

Ә СЕЗНЕҢ БАЛАЛАР ҖӘЙГЕ КАНИКУЛЛАРЫН НИЧЕК УЗДЫРАЧАК?

Алсу Әбелханова,
җырчы:

– Олы улым Әмир быел 5нче сыйныфны тәмамлады. Параллель рәвештә сәнгать мәктәбендә дә белем ала. Шуңа күрә хәзерге вакытта ул ике атналык практика уза. Аннан соң, һәр җәйдәгечә, Ульяновскига әби-бабасы янына кунакка китәчәк. Ә инде бераздан гаиләбез белән диңгезгә ял итәргә барырга дип планлаштырабыз.

Гөлгенә Галимова,
ике бала әнисе:

– Укулар тәмамлангач, кызыбыз ике атна дәвамында мәктәп яны лагерена йөриячәк. Анда дуслары белән дә аралашыр, үзенә яңа шөгыльләр дә табар, дидек. Шуннан соң авылга әбиләренә кунакка кайтыр дип уйлыйбыз. Ә инде июль урталарында, үзебез ялга чыккач, гаиләбез белән бергә Кырымга ял итәргә барырбыз дип планлаштырдык. Балаларның ялларын күңелле, файдалы итеп үткәрәсебез килә. Кызыбыз каникул чорында мәктәпне, укуны бик онытып бетермәсен дип, китап укуын сорыйбыз.

Римма Расчитаева,
Азнакай районы:

– Авыл балалары шәһәрнекеләр кебек иркәләнми инде ул. Мин үзем оныгым Илдарны тәрбиялим. Ул быел 8нче сыйныфны тәмамлады. Бүгеннән каникуллары башлана, әмма берничә көн элек үк ул фермага көтү көтәргә чыкты. Бернинди дә мәҗбүрләү юк, үзе әллә кайчан ук белешеп куйган иде инде. Аның сыйныфташлары да кайсы кая эшкә урнашырга дип торалар. Мәсәлән, берсе шулай ук көтү көтәргә чыкты, икенчесе кырда әтисенә ярдәм итә. Авыл баласы балачактан ук әнә шулай эш белән чыныгып үсә. Мәктәптән соң саф һавада эшләү рәхәтлек бирә аларга.

САН

*2017 елда республика халкының күмәк ял итү урыннарын, парк һәм скверларны санитар эшкәртүгә Татарстан бюджетыннан **30 млн 253 мең сум** акча бүлеп бирелгән.*

ТОП – 3

ТАТАРСТАН Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашындагы «Рубин» футбол клубы попечительләр советы утырышы барышында Илсур Метшинның футбол клубы президенты вазифасыннан китүе билгеле булды. «Мин бу карарга шат», – дип белдерде Казан мэры үзе. Шулай итеп, футбол клубын финанслау һәм идарә итү тулысынча Попечительләр советы «ТАИФ» компанияләр төркеменә тапшырылды.

БӨТЕНРОССИЯ җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәгенең еллык тикшеренүләре күрсәтә: Россиядә бер ел эчендә тәмәке тартучылар өлеше үзгәрмәгән, ул халыкның өчтән берен, 32 процентны тәшкил итә. Сораштырылучыларның 20 проценты көненә бер кап яки аннан артыграк тәмәке тартуын белдергән. Социологлар тәмәке тартуны ташлау теләгенең сизелерлек уңай динамикасын билгеләгән.

КИЧӘ Казанда «Татмедиа» җәмгыятендә яңа акция – «Игелек территориясе» старт алды. Аның кысаларында Татарстанның танылган кешеләре үз мисалында башкаларны да игелекле эшләргә рухландырачак. Әлеге акциядә беренче булып «Татмедиа» генераль директоры Андрей Кузьмин һәм «Татспиртпром» генераль директоры, «Татмедиа» гаммәви матбугат чаралары экс-җитәкчесе Ирек Миңнәхмәтов катнашты.

Рөстәм МИҢНЕХАНОВ,
Татарстан Президенты:

Сүзе күп, төгәллек аз. Сыйфат булмаса һәм безнең предприятиеләр чемпионатта катнашмаса, әзерләнгән белгечләрнең саныннан бернинди дә мәгънә юк. Сезнең ясалма (туфта) имтиханнарыгыз беркемгә дә кирәкми.

(WorldSkills Russia – 2017 һөнәри осталык буенча милли чемпионат нәтиҗәләренә анализ ясаганда, Татарстанның мәгълүматлаштыру һәм элемтә министры Роман Шәйхетдиновны тәнкыйтьләп әйткән сүзләре).

КҮРШЕЛӘРДӘ

Башкортстанның Салават шәһәрендә яшәүче солдат анасы Россия Оборона министрлыгыннан, Оренбург өлкәсендәге хәрби частьта һәлак булган улы өчен, компенсация сыйфатында суд аша 1,5 млн сум акча откан. Аның улы, бүлек командирының янауларын җитди кабул итеп һәм алга таба түбәнсетүләрдән качарга теләп, үз-үзенә кул салган.

Чувашстанда 2019 елдан башлап транспорт салымы артачак. Кертелгән үзгәрешләр нигезендә, транспорт чарасының аерым кагеторияләре буенча, транспорт салымының коэффициенты 1,207гә артачак. Мәсәлән, 100 ат көченә кадәр ия булган җиңел машина өчен бәя 13 сумнан 16 сумга кадәр (бер ат көченә) күтәреләчәк. Мондый машина хуҗалары уртача алганда 261 сумга артыграк акча түләячәк.

Мари Элда 1 июльдән балалар бакчаларына түләү кимеячәк. Бу хакта Йошкар-Ола мэры Евгений Маслов җиткергән. «Балалар бакчаларын ризык белән тәэмин итүне ачык һәм үтә күренмәле итәргә булдык. Бу җитештерүчеләрнең үзләренә аукционнарда катнашу мөмкинлеген бирәчәк. Димәк, 1 июльдән балалар бакчаларына түләү дә бераз булса да кимеячәк», – дигән ул.

АТНА ФОТОСЫ

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

АБАУ!

29 май көнне 100 елга беренче мәртәбә Мәскәүдә узган гарасатта 16 кеше һәлак булды. Гомумән алганда, үлүчеләр 20-65 яшьлекләр. Сәламәтлегенә зыян килүчеләр саны – 170ләп кеше. Һәлак булганнарның туганнары – 1 миллион, зыян күрүчеләр 500 мең сум күләмендә акча алачак. Ата-аналарының берсен югалткан балаларга ай саен 13 мең сум күләмендә акча түләнәчәк. Моннан тыш, амбулатор шартларда медицина ярдәме күрсәтелгән зыян күрүчеләргә 100 мең сум акча биреләчәк.

МАГНИТ ДАВЫЛЛАРЫ

Июньнең беренче атнасында магнит кыры тыныч булачак.

Казан шәһәре мэриясе, әнисе **Гөлдәминә Миннегол кызы РӘХИМОВАның** вафат булуы сәбәпле, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы секретариаты идарәсе җитәкчесе Рафикова Альбина Фәрит кызының авыр югалту кайгысын уртаклаша.

БӘХИЛЛӘШҮ

Илфак Шиһаповка соңгы хат

Мин төн буе синнән хәбәр көттем... «Ачуланма инде, Гөлнара, шаяртып аласым килде...» – дигән сүзләреңне ишетәсем килде. Мин ачуланган булыр идем, син матур итеп елмаеп тыңлап торыр идең... Шалтыратмадың... Аннан элемтәгә чыгып булмыйдыр шул...

Таңда мин сиңа хат язарга утырдым. Дөрес, бу сүзләр инде безнең ике дистә елга якын танышлыгыбыз-дуслыгыбыз чорында бер-беребезгә шактый еш әйтелгән сүзләр, сиңа алар яңалык булмас, әмма мин аларны бөртекләп кәгазьгә төшердем. Баш мөхәррир буларак, мин рәсми сүзләр язарга тиеш булганмыйдыр, әмма без бит синең белән икебез дә андый рәсмилек киртәләрен яратмый торган кешеләр. Шуңа мин соңгы хатымны дустым Илфакка язам.

Кичә синең турында хатирәләремне сорап шалтыраткан журналистларга, без 2002 еллардан бирле таныш, дип әйткән идем. Ялгышканмын. 2000 ел иде ул. Синең «Татарстан яшьләре»нә язып йөргән вакытларың. Риман Гыйлемханов белән бергә безнең районга, алай гына да түгел, авылга килеп «тәртип урнаштырып» йөргәнсез. Төрткеле, ачы язмагыз газетада чыкты. Хуҗалык җитәкчесе, әлбәттә, барысын да миннән күргән: журналистика факультетында укучы кеше мин генә бит, димәк, сезне дә мин китерткәнмен. Ә мин сезне укып беләм, аралашып белмим. Танышырга, аңлашырга киттем. Риман абый белән колач җәеп каршы алдыгыз. Без шул чорда ук бер-беребезне ярты сүздән аңларлык кешеләргә әйләнгәнбездер. Аннан соң «Татарстан яшьләре»ндә бергә эшләдек. Чынлап торып дуслаштык. Кунакларга йөрештек. Сөйләшмәгән сүз калмый иде... Дус та, абый да, киңәшче дә, терәк тә булдың син миңа.

Соңрак син журналистикадан читләштең. «Шәһри Казан»га баш мөхәррир булып билгеләнгәч, мин сине эшкә чакырып шалтыраттым. «Мин журналистикага кире кайтмам дигән идем инде. Син чакырганга киләм», – дидең. Икенче көнне инде эштә идең...

Бөек идең син, Илфак. Уникаль идең. Күпкырлы талант идең. Продюсер, журналист, шагыйрь, композитор, тарихчы, сатирик... Тере энциклопедия идең. Нинди генә өлкәгә караган сорау булмасын – тарихмы ул, сәясәтме, икътисадмы, әдәбиятмы, сәнгатьме – барысына да җавабың бар һәм тәгәл, фактлар белән дәлилләнгән иде. Андыйлар күп булмый. Синең ни дәрәҗәдә олпат булуыңны танырга теләмәгән «бөек»ләрнең, шалтыратып, синең турында әйткән сүзләрен мин елмаеп кына тыңлый идем. Син дә елмая гына идең. Сиңа мактау, дан-шөһрәт, дәрәҗәләр кирәкми иде бит. Син Илфак булуың белән аларның барысын да алган идең инде. Нинди генә тармакта иҗат итсәң дә, син йә елаттың, йә көлдердең, йә ачу чыгарлык иттең, әмма берәүне дә битараф калдырмадың. Бу синең иң зур сәләтең иде – битараф калдырмау! Ялгышларың күп булды, аларны без дә, син дә бик яхшы беләбез. Әле 18 май көнне генә соңгы тапкыр күзгә-күз карап сөйләшеп утырганда да аларны үзең таныдың, төзәтергә теләдең... Өлгермәдең шул... Яшәргә ашыктың... Шул ашкынуың белән үзеңне йончыттың, талкыдың...

Синең соңгы хәбәреңне ишеткәч, шалтыратуларны белсәң... Барысында да бер сорау: «Нинди ярдәм кирәк?» Дусларың да үзең кебек ярдәмчел шул, Илфак. Чиста күңелле, киң йөрәкле кеше идең бит син. Синең кебекләрнең дуслары начар була алмый. Нинди генә ачык булсаң да, теләсә кемне якын уздырмый идең бит, кешеләрне таный идең.

Синең ни дәрәҗәдә зур булуыңны, талантлы, милли җанлы булуыңны без янәшә булганда аңлап та, бәяләп тә бетермәгәнбездер бәлки. Зур сүзләр сөйләми генә, шапырынмый гына эшли идең. Әллә нинди планнарың бар иде бит, әле үзеңне әллә ничекләр күрсәтәсе, ачасы идең. Саклап бетерә алмадык бугай без сине, Илфак... Кичер!

Бәхил бул, дустым!

Гөлнара САБИРОВА.

Расиха ФӘИЗОВА, «Шәһри Казан» газетасының баш мөхәррир урынбасары:

– Илфак Шиһапов турында «иде» дип сөйлисе дә килми. Редакциягә ишектән үк шау-гөр килеп керер ул... һәм киткәнче, без Илфакны ишетәбез, редакциядә барлыгын белеп торабыз, чөнки аның тавышы бөтен коридорны тутырып «басып ала». Кайчан карама, телефоннан нәрсәдер хәл итә, нидер эшли, кемнеңдер хәлен белә, киңәшләрен бирә. Авыллар тарихы турында сүз башланса, монда инде ул конкрет мисалларга, тарихи фактларга күчә.

Аралашырга бик җайлы кеше иде Илфак. Эчендәге тышында иде аның. Эчкерсез, ачык, җор, фикерле... Илфак өчен редакция – беренче чиратта әнә шушы эчкерсез аралашу, фикер уртаклашу урыны булды.

Зөлфия ХӘЛИУЛЛИНА, «Шәһри Казан» газетасының баш мөхәррир урынбасары:

– Ул безнең Балтач якларын миннән дә ныграк яратты бугай. Һәрвакыт «безнең Балтач» дип сөйләште. Хәер, кайсы гына төбәккә барсак та, әлеге җирлек, аның тарихы турында сәгатьләр буе сөйли ала иде. Шул тиклем мәгълүматны, тарихи фактларны ничек хәтердә саклый икән дип хәйран калып тыңлый идем. Аның белән бергә ничәмең чакрым юллар үтелгән... Авылга килеп керүгә, ул кеше күрмәгәнне күреп ала торган иде. Күрә һәм барысын күңеленә сеңдерә бара. Гади кешеләрне аның кебек беркем дә ярата алмас. Аның яратуы башкача иде шул. Хөрмәт тә, аларның йөрәктәгесен аңлау да. Ул узган тормыш мәктәбе аны әнә шулай сизгер күңелле иткәндер, күрәсең. Мәктәптә укыганда ук фермада эшли башлый, үз куллары белән кирпеч салып йорт җиткерә, төзелештә дә эшли. Аннан соң журналистикага кереп китеп, бик тиз арада халыкның хөрмәтен казана. Ә инде аның җырлары... һәр нәрсәнең тәмен табып, җиренә җиткереп, йөрәк аша үткәрә иде ул. Моңа аның сизгер, бик тә нечкә күңеле түгел, корыч та чыдамас...

Илфак ШИҺАПОВ

* * *

...Булды инде, әйдә тәмамлыйк,
Үз юлларыбызга кузгалыйк.
Үтик инде әйдә йоласын –
Тагын бер кат күңел еласын...

Яраланган йөрәк, түз инде,
Ярату ул бары – сүз инде.
Бер кузгалган, әйдә туктамыйк,
Булды инде, әйдә тәмамлыйк...

* * *

Күккә карап, сиңа телим теләк,
Шуны сорый бүген минем йөрәк:
«Бәхетле бул, акчаң булсын димен,
Булсын бик акыллы, яратучы ирең –
Ул кичерсен синең гөнаһларны,
Бәгыреңне читкә таратканны...

Балаларың булсын сау-сәламәт,
Һәр көн тоеп яшә җирдә рәхәт.
Тәңрем! Ялгышлардан сакла аны,
Гел яхшыдан булсын бар булганы.
Эшең барсын, ирең хыялыңа,
Ак җәймәләр синең юлларыңа...»

Күккә карап, сиңа бәхет телим,
Кайсы теләк кабул булыр – белмим,
Ләкин шуны беләм, һичбер сүзсез –
Син бәхетсез булсаң, мин бәхетсез...

* * *

Яндырам күңелнең
Иң нечкә кылларын,
Буталды язмышлар –
Адашты юлларым.

Берни дә кирәкми,
Бар тормыш – чүп кенә.
Яндырам андагы
Саташып сөюнең
Иң изге булганын,
Беренче булганын.
Яндырам күңелнең
Иң нечкә кылларын...

* * *

Берәр кайчан бөтен юлны үтеп беткәч,
Кемдер күктән: «Улым, тукта, җитте!» –
дигәч,
Шуннан илче көтеп тик ятканда
«Юкка яшәмәдемме?» – дип уйлаганда
Искә төшәр әле бүгенге көн,
Синең белән булган һәр изге төн:
Бер матур төш кебек булыр алар,
Син кочакта чакта – саташулар,
Бер үкенеч калыр бу язмыштан
Бергә буталмаган буш тормыштан.
Шунда әйтер күкләр: «Очраштырдым.
Очраштырдым, таныштырдым,
кавыштырдым.
Бар дөньядан куркып сөештегез,
«Кеше генә белмәсен тик!» – диештегез.
Үкенмәгез, ул тормышны хак санагач,
Кеше сузе бәхеттән дә кыйммәт булгач.
...Берәр кайчан бөтен юлны үтеп бетәм,
Күктән: «Булды, улым!» – дигән сүзне көтәм...
Җавап итеп күккә кычкырырмын:
«Мин яраттым, мин яратам,
яратырмын...»

Мөдәрриснең бар ялганы чыгар әле бер дөрескә!

ҮТЕП БАРЫШЛЫЙ

Равил САБЫР

«Хатыныгызга күбрәк саф һавада йөрергә кирәк, паркларга ешрак барыгыз, катнаш урман һавасы тагын да әйбәтрәк булыр иде аңа», — диде табиб. Ул чакта хәләл җефетем беренче улыбыз Рәзим белән авырлы иде, токсикоз белән бик нык интекте. «Катнаш урман» дигәнне ишетүгә, мин шундук Аккош күлен искә төшердем. Ркаил Зәйдулла, Равил абый Фәйзуллин берничә мәртәбә үзләренең дачаларына кунакка алып барганнар иде.

Ркаилгә шылтыратып, аның йортында бер-ике атна яшәп торырга рөхсәт сорадым. Ул шундук риза булды, тик: «Идәннәр бик ныклы түгел инде анда, алыштырасы бар иде дә, гел кул җитми, чамалабрак йөрерсез», — диде.

Авырлыгым ул чакта да Аллага шөкер иде, шуңа күрә беренче көнне үк минем гәүдәм астында идән түзмәде, җимерелеп төште. Әле дә ярый күршедә Мөдәррис Әгъләмов (безнеңчә — Әкә) тора иде. Аның белән урманга барып имән кисеп аудардык та, алып кайтып, өрлек урынына шуны салдык. Шулай итеп азмы-күпме йөрешле булды өй эчендә. Сүз уңаеннан, Ркаилнең дачасы стандарт фин йортының яртысын биләп тора иде.

Көндез мин эштә, кичләрен Әкә белән учак ягып, уха пешереп, гөмбә кыздырып, бәрәңге тәгәрәтеп, сәгатьләр буе сөйләшеп утырабыз. Бар сөйләгәннәре дә истә түгел инде хәзер, тик бер кыйссасы күңелгә бик нык уелып калган.

— Хәсән ага Туфанның сары тышлы дәфтәре бар иде, — дип сөйләде Әкә. — Ул анда шагыйрьләргә язган эпиграммаларын туплап барган. Сибгат Хәким һәрвакыт властьтагы кешеләргә якын булган, аның фатиры да обком бинасына терәлеп торган биш катлы йортта иде. Ә халыкта иң билгеле шигыре, әлбәттә инде, «Күңелем Ленин белән сөйләшә». Шуңа күрә Хәсән ага аның турында болай дип язган:

Аллә кемнәр белән
сөйләшә ул,
Ә хөкүмәт тормый
хакыннан!
Яхшы ат кебек башын
югары күтәреп
Чыгып килә обком
артыннан...

Мин, киресенчә инде, 60нчы еллардан бирле: «СССР бетәчәк! Советлар Союзы таркалачак! Империяләрнең берсе дә мәңгелек түгел!» — дип кычкырып йөри идем, шуңа күрә минем алдакчы дигән даным чыкты. Ә Хәсән ага дәфтәренә болай дип язып куйган:

Кагылмагыз Мөдәррискә!
Тимәгез Мөдәррискә!
Мөдәрриснең бар ялганы
Чыгар әле бер дөрескә!

Ә Зөлфәт бай кызга, Казан кызына өйләнде. Туйда бабасы аңа төлке тун бүләк иткән иде. Берсендә Зөлфәт рестораннан кайтышлый Хәсән агага кергән, таксига түләргә акчасы калмаган, бурычка биш сум акча алып торган. Хәсән ага Зөлфәтне урамга кадәр озата чыккан, биш сум акча биреп, таксига утыртып җибәргән. Өенә кергәч, сары тышлы дәфтәргә болай дип язып куйган:

Пушкин кебек төлке
тунын салып атып
Сикереп кенә төште
чанадан.
Әйбәт шагыйрь! Һай бик
һәйбәт шагыйрь!
Ни өчендер бүген
салмаган...

Икенче көнне, эшкә баргач, шушы шигырьне Зөлфәт абыйга сөйләп күрсәттем. Без аның белән көн саен диярлек көрешеп тора идек, чөнки мин сигезенче катта «Татарстан яшьләре»ндә эшли идем, ә ул тугызынчы катта «Чаян»да. Еш кына баскыч янына чыгып бергәләп тәмәке көйрәтә торган идек. Укып күрсәттем дә әйбәт шагыйрь турында сорадым:

— Зөлфәт абый, бу шигырьне беләсеңме син? — дим.

— Белә-ә-әм! Ничек инде белмәскә? — дип, балаларча үпкәләгәндәй әйтеп куйды шагыйрь. — Бу бит теге Хәсән аганың сары тышлы дәфтәрендәге шигырь. Ул аны Мөдәррис турында язган!

Кычкырып көлеп җибәрүемне сизми дә калдым, чүт баскычтан мәтәлеп китмәдем ялгыш.

Күпмедер вакыт узгач, «Идел»гә хикәя илткән идем. Чәй эчкән арада, Ркаилгә шушыларны барысын да кызык итеп сөйләдем. Ул исә, гадәтенчә, теләмичә генә ирен чите белән елмаеп куйды да: «Менә Сабыр, шигърияттә саерак йөзәсең шул син, шуңа күрә бу хәлләрнең кызыгын тулысынча аңлап бетерә алмыйсың. Хәсән аганың бернинди сары тышлы дәфтәре дә юк, бу шигырьләрнең барысын да Мөдәррис үзе язган», — диде.

Әлмәт
2017 ел, май.

ЯЗГАНГА КИРЕ КАЙТЫП

АВЫРУ ЕГЕТНЕ АЛЫП КИТҮНЕ АТА-АНАЛАР СОРАГАН

Узган санда блоггер, алып баручы Айсылу Леронның инвалид энесен, имеш, кеше куркыта дип, «Парк Хаус» сәүдә үзәге сакчылары урамга чыгарып җибәргәннәре турында язган идек. Бу мәсьәләгә карата «Парк Хаус» сәүдә үзәгеннән җавап алдык. Кибет администрациясе аңлатуынча, ата-аналар балалар мәйданчыгында «20 яшьләр тирәсендәге яшь егетнең балалар белән бергә сикереп уйнаганына» зарланып, сакчыларга мөрәҗәгать иткән. Алар, бу егет балаларга зыян китерергә мөмкин дип, аны алып китүне сораганнар. Сакчы мәйданчыктан китәргә кушса да, егеттән бернинди дә җавап булмагач, аны йә психик яктан авыру, йә психотроп матдәләр кулланган дип уйлаганнар. «Кызганычка, бу авыру егет озатучысыз, берүзе генә иде, сәүдә үзәгенә төрле кешеләр керә, наркоманнар да булырга мөмкин, шуңа да сакчы куркынычсызлык чараларын күргән, егетне мәйданчыктан чыгарганда көч кулланылмаган. Ничек кенә булмасын, кызганыч хәл», – диделәр сәүдә үзәге администрациясендә.

«Төнге корбан»: ышанумы, табынумы?

Чувашия республикасының Комсомол районы Урмай авылы урамы буйлап барганда, күзебез бер гаиләнең бакча уртасында рәшәткә белән тотып алынган агач төбенә төште. Моның нинди дә булса бер хикмәте бардыр дип, бу турыда авыл халкыннан сорарга булдык. Гөлназ Хәмдиева аңлатуынча, әлеге урында кайчандыр «изге куак» үскән. Бактың исә, бу авылда яшәүче берничә гаилә «төнге корбан китерү» йоласын башкара икән.

– Әлеге йола безнең авылның берничә гаиләсендә буыннан-буынга тапшырылып сакланып калган. Безнең гаиләдә дә бар. Әнигә ул каенанасыннан күчкән. Һәр ел саен бер казны башкалардан аерып алып кала да үзен аерым гына чалдыра. Аны көндез чистарта да, каз шулпасында ботка пешереп, балаларны, оныкларны, иң якын туганнарны кунакка дәшеп, сый-хөрмәт күрсәтә. Әмма башкалар ашый башлаганчы, дога укылгач, аерым бер савытка каз итенең һәм ботканың бер өлешен алып куя. Шуннан соң төн җиткәч, казның сөякләрен, йоннарын, пычрак суларын, ташланырга тиеш булган башка әгъзаларын һәм аерып алып куйган ризыкны алып, махсус урынга илтеп күмә. Шул рәвешле төнге корбан китерә. Кемдер ул урынга куак, агач утырта, ә кемдер, киресенчә, буш урын сайлый, – диде ул.

Гөлназ ханым әйтүенчә, йоланың үз тәртипләре дә бар икән. Мәсәлән, төнлә суларны түгәргә барганда һәм кире кайтканда бер сүз дә дәшәргә ярамый. Аннан соң каз шулпасында пешкән ботканы да, итне дә кунаклар шул ук көнне ашап бетерергә тиеш икән.

– Тик бу йоланы һәр гаилә дә башкарырга теләми, чөнки бөтен кешегә дә килешеп бетмәскә мөмкин. Ышанмаучылар, «шайтан корбаны» дип әйтүчеләр дә күп. Ә кайберәүләргә, киресенчә, файдасы тия. Икетуган абыйның хатыны әлеге йоланы каенанасыннан кабул итеп алган иде. Ә каенанасы аңа бөтен тәртибен дә аңлатырга өлгермәгән булган, чөнки бергә озак яшәп кала алмадылар. Килен булып төшкәч, каенанасы үлеп китте. Шушы корбан китерү вакыты җиткәч, килен кешенең кул сөякләре авырта, тавык аягына охшый башлады. Шуннан соң туганнары каенанасының корбанга каз түгел, ә тавык чалуы турында әйткән. Аны да дога укучы әбигә генә илтеп бирә торган булган. Килен шулай эшли башлагач, терелде. Озак вакыт авыручылар арасында корбан китергәннән соң савыгучылар да бар, – диде безгә Гөлназ ханым.

Шунысы кызыклы: әлеге йола фәкать шушында гына сакланган, якын-тирә авылларның башка берсендә дә юк икән.

Зәһрә САДЫЙКОВА.

«Бәхетле көннәрем алда әле»

Авыру егетнең җәйне авылда уздырасы килә

Кешене өмет, хыял яшәтә! Казан егете Самат (фамилиясен күрсәтүне теләмәде) белән танышып сөйләшкәннән соң, мин әнә шундый фикергә килдем.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Самат – бер бүлмәле фатирында ялгызы гына гомер кичерүче II группа инвалид. Моңа кадәр дә мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр белән шактый күп аралашырга, алар турында язарга, өйләренә барырга туры килгәне бар. Ялгызлары гына яшәп ятучы авыру кешеләрнең йортына килеп кергәч, күпчелек очракта, иң элек борынга ят ис килеп бәрелә торган иде. Әмма бу юлы мине чиста-пөхтә итеп җыештырылган фатир каршы алды.

– Ярдәм итүче кешегез бармы соң? – дигән соравыма каршы:

– Әниемнең танышы ярдәменнән ташламый. Атнага бер-ике тапкыр килеп өйне җыештыра, кибеттән азык-төлек алып кайта. Тик мин һәрвакыт: җыйган өй түгел, ә чүпләмәгән өй чиста дим, – дип елмая фатир хуҗасы Самат.

Яңа танышым үзе, тормышы турында сөйләргә артык яратмый.

– Миңа ярдәм итәргә теләге уянган кеше өчен тормыш юлым, яшем, фамилиям мөһим булмас дип уйлыйм, – дип аңлата ул үзе моны.

Шулай да тормышының кайбер вакыйгаларына тукталасы итте.

Самат туганда ук җәрәхәт алган булган, әти-әниләре аны дәвалар өчен бөтен көчләрен куеп, аякка бастырган. Шуннан соң гадәти балачак, мәктәп еллары… Егылу аркасында алынган җәрәхәт Саматның тормышын кыл икегә бүлгән. Җитмәсә, әнисе бик яшьли үлеп китә, берничә елдан әтисе дә гүр иясе була. Шушы авырлыкларга карамастан, ул урта һөнәри белем ала, эшли, авыруы азып, хәле начарланганчыга кадәр командировкаларга да йөри.

– Әгәр әти-әнием исән булса, миңа бүген күпкә җиңелрәк һәм яхшырак булыр иде. Янымда якыннарым, туганнарым, дусларым җитми. Соңгылары минем бервакытта да күп булмады. Минем өчен сан түгел, сыйфат мөһим иде. Ә авырып киткәнче музыка белән шөгыльләнә, шахмат, техника, тарих белән җитди кызыксына идем. Табигатькә чыгарга, хайваннар белән аралашырга яратам. Хәзер дә өйдән торып кына эшләр идем дә, күзләрем начар күрә башлагач, компьютерда утыра алмыйм, – ди ул.

nevzaterdag.com

«ХЫЯЛЛАНЫП ЯШИМ»

Язманы хыял, өмет дигән төшенчәләрдән башлаган идем. Сәламәт чагында бөтен Казанны аркылыга-буйга җәяүләп узган кеше буларак, Самат трейлерда (тәгәрмәчле йорт) сәяхәт итәргә хыяллана.

– Мин максатыма ирешүчән кеше. Сәламәтлегем начар булуына карамастан, трейлерда хәрәкәт итәргә хыялланам. Ни өчен нәкъ шуңардамы? Чөнки авыруым аркасында башка төрле ысул белән сәяхәт итү мөмкин түгел. Әгәр миңа ярдәм итүчеләр табылса, бик шат булыр идем. Кешеләр белән аралашырга, башка җирләрне күрергә, табигатькә чыгарга телим, – ди ул.

Әле алай гына да түгел, трейлерда сәяхәт итеп, инклюзив кино төшерергә дә хыяллана. Анда ул мөмкинлегә чикле кешенең әйләнә-тирә мохит белән аралашуы турында сөйләр идем, ди.

Өендә акрын гына йөреп торса да, урамга чыкканда ул кеше ярдәменә мохтаҗ. Самат һава җитмәүдән, кулларының хәлсезлегеннән зарлана. Җәй көне шәһәр һавасы аеруча да авыр, ди. Шуңа күрә дә ул ямьле җәй айларында үз гаиләсенә сыендырырга риза булган мәрхәмәтле гаилә яки берәр кеше белән танышырга өметләнә.

– Җиде мең пенсия алам. Әгәр шушы акчага риза булып, миңа ярдәм итәргә теләүче кеше табылса, бик бәхетле булыр идем. Моңа кадәр дә төрле урыннарга мөрәҗәгать иткәнем булды, тик ярдәм итүче табылмады. Шулай да мин бик оптимист кеше. Әлегә хыялларым чынга ашмаган икән, димәк, вакыты гына килеп җитмәгәндер. Гомумән, нинди вариант, мөмкинлек бар – барысын да кулланып карарга кирәк. Мин шулай эшлим дә. Юлымда миңа ярдәм итәргә әзер булган кешеләр очраячагына да ышанам. Тормыш бик гыйбрәтле бит ул. Аның бормалы-сырмалы нинди генә юллары юк. Бүген-иртәгә ни буласын бер Алла гына белә. Шуңа күрә иң бәхетле көннәрем алда булачагына һичшиксез ышанам, – дип озатып калды мине көчле рухлы Самат.

Самат мәсьәләсе буенча без республиканың Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгына чыктык. Әмма анда, авыруга берничек тә ярдәм итеп булмый, дип аңлаттылар. Шуңа күрә, газета укучыларыбыз, бөтен өмет сездә. Бәлки, сезнең арада әлеге егеткә ярдәм кулы сузарга теләк белдерүчеләр табылыр?

ЯЗМЫШ

Бер күрешү – бер гомер

Тау белән тау гына очрашмый, диләр. Хак. Күптән түгел генә миңа дулкынландыргыч очрашуның шаһиты булырга туры килде.

Ульяновск каласында яшәүче әниемнең апасына гаиләбездәге яңалыклар турында телефон аша гел хәбәр биреп торам. Бер сөйләшкәндә, Равия апага Балык Бистәсенә кунакка баруыбыз турында да әйттем. Бу район аның яшьлек хатирәләре белән бәйле икән. Яшь чагында Казанда ашханәдә эшләгәндә, Балык Бистәсе Олы Әшнәк авылыннан Гөлсем исемле кыз белән дуслашкан булган.

Апа – тормышның ачысын-төчесен шактый татыган кеше. Сугыш башланган елның июнь аенда дөньяга килгән. Казанга да рәхәт тормыштан чыгып китмәгән. Бу вакытта инде ул кияүгә чыгып, бәби тапкан булган. Ләкин язмыш юлының кайчан син дигәнчә генә баргане бар?! Яшьли яратышып, бер-берләреннән башка яши алмыйбыз дип вәгъдәләр бирешсәләр дә, мәхәббәтләре озакка бармый. Аерылышалар. Кечкенә улларын каенанасы алып кала. Шактый йокысыз төннәрдән соң, яңа тормыш башлап карарга дип килә апа Казанга. Бар белеме авыл мәктәбеннән узмаган кызга ярый әле ашханәдә эш табыла. Авызы бер кат пешеп, шактый кыен татыган апам, ахирәте Гөлсемне ялгышлардан саклап калу өчен, киңәшләрен кызганмый. Дуслыклары көннән-көн ныгыган кызлар бер-берсенең туган нигезләренә – Балык Бистәсенең Олы Әшнәк һәм Буа районының Вольный Стан авылына кунакка да кайтып киләләр.

Тора-бара кызларның юллары аерыла. Гөлсем, авылларындагы Камил исемле егеткә кияүгә чыгып, үз якларына кайтып китә. Апамның да башкалада әчәсе суы күп калмаган була, күрәсең. Ялгызлыктан аптырап, хатыны каршына ялынып килгән ирен гафу итеп, ул да Ульяновскига китә. Малайларын да үз яннарына алып, яңадан тулы гаилә булып яши башлыйлар.

Баштарак ахирәт кызлар арасын хатлар тоташтыра. Аннары һәркем муеннан тормыш мәшәкатьләренә чумгач, җитмәсә, апам тору урынын да алмаштыргач, элемтә бөтенләй өзелә.

Минем Балык Бистәсе турында сөйләвем апамның шул яшьлек хатирәләрен яңартып җибәргән икән бит. Ул: «Кайсы авыл? Әшнәк түгелме?» – дип сорап куйды. Балык Бистәсендә Әшнәкләр икәү: берсе – Кече, икенчесе – Олы. Без кайтып йөри торганы – Кече Әшнәк. Бәхеткә, безнең дуслар Гөлсем апаны белә, хәтта чак кына туганнары, кодачамы да тиеш булып чыктылар. Тиз генә телефон номерын да табып бирделәр. Озакка сузмый гына, әлеге номерны җыеп, Равия ападан сәлам җиткердем. Гөлсем апа минем ахирәтенең сеңлесе икәнемне белгәч, бик шатланды. Аннары мин дә кош тоткандай сөенеп, Гөлсем апаның телефон номерын апама җиткердем. Ул шатлыгын ничек белдерергә белмәде. Елый-елый, миңа теләкләр теләде. Еракта калган яшьлекләрен сагынып, телефоннан сөйләшеп туя алмаган ак яулыклы ике намаз карчыгы. Күңелләрендә: «Ходай очрашу да насыйп итсен иде инде», – дигән теләк тә була.

Апрель аенда минем юбилей булды быел. Өйгә дә нур иңәр дип, Коръән мәҗлесе үткәрергә булдык. Әлеге мәҗлескә Равия апа беренчеләрдән булып әзерләнә башлады дисәм дә, ялгышмам. Аны да аңларга була, Казанга килсә, дусты яшәгән Балык Бистәсенә дә ерак калмый бит. Аның ниятен белгәнгә күрә, без дә бу ике карчыкны очраштыру турында уйлаша башладык. Рәхмәт инде, Кече Әшнәктәге дусларыбыз мәҗлескә Гөлсем апаны да алып килергә булдылар.

Гадәттә, мондый дулкынландыргыч мизгелләрне киноларда йә «Жди меня» тапшыруында гына күрергә мөмкин. Иңнәрендә озын гомер йөге булган ике карчык, бер-берләренең кочакларына сеңеп, шактый вакыт: «Төш түгелме бу?» – дигәндәй, суларга да куркып басып тордылар. Аннан бер бүлмәгә кереп китеп, туйганчы серләштеләр. Мәҗлес башланыр алдыннан гына чыкты алар, икесенең дә күзләрендә яшь иде. Аларны аңлавы авыр түгел, арада күрешмәгән, аралашмаган 49 ел. Ныклап уйлап карасаң, үзе бер гомер. Равия апаның да сөйләр сүзләре күп. Ул инде дәү әни генә түгел, инде оныгының улы бар. Яраткан ире белән ике бала: бер кыз, бер малай үстергән, бәхетен туган җирендә тапкан, гомерен ашханәдә эшләп уздырган Гөлсем апа да – өч оныкның яраткан дәү әнисе. Ире генә бакыйлыкка иртәрәк киткән.

…Гомер йомгакларын бер сүтеп, бер чорнап, хатирәләр диңгезендә озак йөзде алар ул көнне. Иң мөһиме: икесе дә бик бәхетле иде алар, хәтта яшәреп киткәндәй тоелдылар.

Йолдыз ШӘРАПОВА.

ҮЗАРА САЛЫМ:
канәгатьсезләргә җавап

Үзара салым турында ишетмәгән, белмәгән, аны «татып» карамаган кеше юктыр. Җирле бюджетлар керемен тулыландыра торган иректе салым системасы федераль күләмдә ун еллап элек кертелде.

Зөлфия ХӘЛИУЛЛИНА

Автор фотолары

Аның күләмен, нәрсәгә тотылачагын авыл халкы үзе хәл итәргә тиеш. 2013 елдан халыктан җыелган салым дәүләт тарафыннан финанслана, ягъни халыктан җыелган бер сум акча дүрт сум булып әйләнеп кайта. Үзара салым акчасы турында һәр җирлекнең генә түгел, һәр гаиләнең үз фикере бар дисәм дә, ялгыш булмас. Берәүләр хуплый, икенчеләре, бар нәрсәне халык өстенә калдыралар дип, ризасызлык белдерә. Кайдадыр халыктан 150-200 сум акчаны көчкә җыялар, ә менә Әтнә районының Түбән Бәрәскә авыл җирлегендә яшәүчеләр өченче ел рәттән үзара салым акчасын гаиләдәге һәр кешегә 1000 сум исәбеннән җыйганнар! Әлеге авыл җирлегенә Бәрәскә, Бәрәзә, Өшкетә авыллары керә. Димәк, гаиләдә дүрт кеше икән – дүрт мең, алты кеше икән, алты мең биргәннәр. Бер карасаң, аз акча түгел. 200 сум акча бирмәскә җан тартышып торган кешеләрне белгәннән һәм күргәннән соң, гаҗәпләнү бермә-бер арта.

Халык ничек кабул иткән? Эшне ничек оештырганнар, халыкны ничек ышандырганнар? Каршылыклар булмаганмы, ышаныч акланганмы? Әлеге сорауларга җавап табу өчен, Әтнә районына юл тоттык.

Үзара салым акчасын җыйнау, халык белән эшләү җирле үзидарәләргә тапшырылган. Бәрәскә җирле үзидарә рәисе Аида Фатыйхованы, әле генә монда иде, чүп түядек, өстен алмаштырырга кайтып китте, диделәр. Ул арада ул үзе дә килеп җитте.

– Әйе, безнең җирлектә үзара салым һәр кешедән бер мең сум исәбеннән җыйнала. Аның дәүләт ярдәме белән дүрт тапкыр артуын да исәпләсәк, шактый сумма чыга. 2016 елда өч авылга 5 млн 560 мең сум акча җыйналды. Һәр авылның үз акчасын үзенә тотабыз. Авыл халкы белән сөйләшеп, бүгенге көндә авылның яшәеше, тормышы өчен нәрсә кирәк, бүгенге көндә кайсы мөһимрәк икәнлеген билгелибез, – ди Аида ханым.

– Халык авырсынмыймы?

– Мин халыкка бик рәхмәтле. Бирмибез дип каршы төшкән кеше юк. Без дә, үз чиратыбызда, халык акчасының бер тиенен дә юкка сарыф итмәскә, мөмкин кадәр күбрәк эш башкарырга тырышабыз. Өшкетә авылының юллары бик беткән иде. Бөтен технологияләргә туры китереп, иң элек юлны грейдер белән эттереп, ком, аның өстенә таш салдык. Бер машина комның, ташның бәясен һәркайсыбыз беләбез. Авылыбыз өлкәннәре китерелгән һәр йөкне үлчәп, язып барырга куштылар. Без шулай эшләдек тә. Халык акчасы булгач, монда шикләнүләргә урын калмаска тиеш. Әгәр дә «Ленин» хуҗалыгы, аның җитәкчесе Илгиз Хәйруллин булышмаса, җирле үзидарә үзе генә бу тиклем эшне оештырып, башкарып бетерә алмас та иде. Һәр эшне башлар алдыннан, без аның белән киңәшәбез. Каян нәрсәне түбәнрәк бәягә алып була, кайсы сыйфатлырак, кемнәр эшне намус белән башкарып чыга? Боларның барысын да Илгиз Вилдан улы белешә, киңәшен бирә. Әлбәттә инде, матди яктан да ярдәм зур. Авыл юлларын караганда, елгаларга салырга 540 диаметрлы унике торба гына биреләде. Хуҗалыкның экскаваторы белән юл читләренә канаулар казылды. Авылны, аның халкын кайгыртып торучы җитәкчебез булу белән без бик бәхетле. Җирле үзидарә авыл хуҗалыгы белән бер булып, хәбәрләшеп эшлибез. Үзара салым акчасына зират коймаларын яңартырга материал алдык, халык өмә белән эшләде. Зиратның капкаларын да яңарттык. Шулай ук зиратларда, җирләү өчен кирәкле булган әйберләрне саклау өчен, будкалар эшләттек. Ут-күз булса, су алу өчен дүрт гидрант куелды. 840 метр арада су торбасын алмаштырдык. Алла боерса, үзара салым акчасының быелгысына юлга таш түшәп бетерергә, мәктәп янындагы күлне карарга, Бәрәскә авылы урамындагы асфальтның ватык урыннарын ремонтларга, зират коймаларын тотып бетерергә исәплибез.

Аида Фатыйхова белән авыллар буйлап йөреп, барлык башкарылган эшләрне карап чыктык. Җирле үзидарә рәисенең эше тыгыз: әле берсе шалтырата, әле икенчесе. Миңа да форсат чыкты, ул сөйләшкән арада, авыл белән бәйле хатирәләрне барлап, урам буйлап киттем. Бәрәскә авылына иң беренче тапкыр моннан ун еллар элек чәчү вакытында килергә туры килгән иде. Бөтен дөнья ямь-яшел, җир яхшы камыр кебек өлгереп җиткән, механизаторларның барысы да кырда. Аннан соң урып-җыю чорында булдым, кырларның иркенлеге, уңышның муллыгы күңелнең иң түренә матур хатирәләр булып кереп урнашты. Сирень чәчәк атканда килгәнмен икән әле тагын бер, бу юлы исә шомырт чәчәкләре каршылады. Авылның табигате, кешеләре, аларның башкарган эшләре тулы бер картина тудырып, хәтергә сеңә бара. Бәрәскә авылы гел җете төсләрдән тора. Бу юлы да никадәр яңалык. 1769 елда салынган таш мәчет – авылның горурлыгы. Аны, тарихи объект буларак, сафка бастыру өчен зур эшләр алып барыла. Шулай да әле сәгате сугып җитмиме, төзекләндерү эше тулы көченә башланып китә алмый. Дәүләттән дә азмы-күпме ярдәм бар, «Ленин» хуҗалыгы да булыша, алар янында меценатлар да булса, эш кузгалыр иде, ди халык. Бу юлы аның янына бик матур итеп кое ясап куйганнар. Элеккеге кое урыны булган икән. Кайчандыр иске кибет булган бинаны өр-яңадан ремонтлап, хәләл кафе ачканнар. Андагы зәвыклылык сүз белән генә әйтеп бетерерлек түгел. Авыл җирендә мондый кафелар күреп күнекмәгәнгә, гаҗәпләнүнең чиге булмады. Иң мөһиме: ул бизәк булып кына тормый, авыл халкына хезмәт итә. Түбән генә бәядән хәләл ит, казылык, камыр ризыкларының ниндие генә юк. Җаның ни тели, бар да мулдан. Сыйфатлы, хәләл. Никах туйлары, Корьән ашлары үткәрергә менә диган залы да бар.

Кабат үзара салым акчасына әйләнеп кайтабыз икән, аның уңай яклары барыбер күбрәк. Башкарылган эшләр бер, җимерелгәнне күрергә, яңартылганны сакларга, үзенә хуҗа булырга өйрәтә ул халыкны. Сүз дә юк: җирлектәге хуҗаларның эшне оештыра, халык белән эшли белүе һәм ышанычны аклаулары әлеге очракта иң мөһиме. Әйткәнемчә, без аның иң матур үрнәген Әтнә районының Түбән Бәрәскә авыл җирлегендә күреп кайттык.

«Шәһри Казан»нан – алма бакчасы

Узган атнада алмагач откан Рузилә Абдуллина Казанның 162нче балалар бакчасында өлкән тәрбияче булып эшли. Ул, балаларның күңелләрендә табигатькә сакчыл караш, хезмәткә мәхәббәт уяту максатыннан, бүләген балалар бакчасына тапшырырга карар кылган. Күмәкләшеп алмагач утыртканнарын безгә дә төшереп җибәргән. Моннан тыш, балалар белән «Нәни мичуринчылар» дигән проект та башлаганнар. Әлеге проект кысаларында, алар алмагач турында хикәяләр төзегәннәр, үзләре ясаган рәсемнәрне редакциябезгә дә бүләк иттеләр. Әти-әниләр дә бу эштә теләп катнашкан. 162нче балалар бакчасы мөдире Рәсимә Вәлиева әйтүенчә, алар әлеге алмагачка «Киләчәк» дип исем кушканнар, шунда ук «Шәһри Казан» дип язылган элмә такта да куйганнар.

– Бу алмагач ничә елдан җимеш бирәчәген, алмадан кайнатма, компот, алма салып пешергән камыр ризыклары әзерләвебез турында да сөйләшеп, хыялланып алдык. Ә иң мөһиме – без алмагач бакчасында «Шәһри Казан» укыячакбыз, – ди 4нче төркем тәрбиячесе Илгизә Садыйкова.

Исегезгә төшерәбез, алмагач үсентесенә ия булу өчен, 2017 елның II ярты еллыгына «Шәһри Казан» газетасына язылырга һәм квитанция белән анкетаны тутырып, редакциягә юлларга кирәк. Җиңүче очраклы саннар генераторы ярдәмендә билгеләнә.
Бу атна җиңүчесе – Әтнә районының Күшәр авылыннан Флюра Нуретдинова. Котлыйбыз!
Чираттагы җиңүчене 15 июнь көнне билгеләячәкбез.

ИНДЕКСЛАР

П2430 – пәнҗешәмбе саны, ярты елга язылу бәясе – **450 сум.**

П2395 – атнага өч тапкыр: сишәмбе, пәнҗешәмбе, җомга көннәрендә чыга, ярты елга язылу бәясе – **930 сум.**

АНКЕТА

1. Исем-фамилия, адрес, телефон________________
____

2. Яшегез___________________________

3. Шөгылегез_________________________

4. «Шәһри Казан» газетасын кайчаннан бирле алдырасыз?_______________________
____

5. Газета белән беренче тапкыр ничек һәм кайда таныштыгыз?_____________________
____

6. Газетага ничек языласыз:

почта бүлекчәсендә _____

хат ташучы өйгә килә _____

интернет аша _____

____

7. Газетаны кайсы битеннән укый башлыйсыз?
____

8. Сезне нинди өлкәдәге язмалар җәлеп итә?
____
____

9. Газетада тагын нинди темаларның күтәрелүен телисез?_____________________
____

10. Газетаның миңа иң ошаган:_____________
____

ошамаган яклары:_______________________
____
____

11. Тагын нинди газета-журналлар алдырасыз?
____
____

«Болан – акыллы хайван»

Узган атна ахырында Татарстан урманнарына дүрт тимгелле болан һәм сигез маралны кыргый табигатькә җибәрделәр. Әлеге вакыйганы тарихи дип әйтергә кирәк, чөнки Кызыл китапка кертелгән әлеге хайваннар безнең урманнардан 200 ел элек юкка чыккан булган. Балык Бистәсе районының Шомбыт авыл җирлегенә кергән элеккеге Степановка авылы урынында урнашкан «Кыргый ферма» фермерлык хуҗалыгы җитәкчесе Альберт Камалиев әйтүенчә, аларны моннан өч ел элек Алтайдан алып кайтканнар. Бу көнне табигатькә җибәрелгәннәре исә читтән кайтартылган түгел, ә Татарстанда туып-үскәннәр. Аларга инде өч яшь.

tatar-inform.ru

– Әгәр без Алтайдан алып кайткан маралны ирекккә чыгарып җибәргән булсак, ул туган җирен эзләп киткән булыр иде. Шуңа күрә без, чит илләргә барып озак өйрәнгәннән соң, нәкъ менә Татарстанда туган, безнең климатка тулысы белән җайлашкан хайваннарның монда яшәп китә алачагына төшендек. Дөресен әйтергә кирәк: тимгелле боланнар да, мараллар да бирегә бик авыр ияләшсә дә, без аларның берсен дә югалтмадык, – ди Альберт Камалиев.

Ул вакытта 43 баш хайван алып кайтканнар. Ә хәзер аларның саны 100гә җиткән, биш елдан соң 300 башка кадәр арттыру планы бар. Тимгелле боланнар һәм мараллар ел саен 20 баш үрчем бирә икән.

Фермерлык хуҗалыгында эшләүче кешеләр әйтүенчә, табигатькә җибәрелгән хайваннар Лаеш, Теләче һәм Питрәч районнарына барып җитәргә тиеш. Шулай да аларны туып-үскән җирләренә кире кайтмас, дип өздереп әйтүче булмады. Ә инде «кунакка килгән» очракта, хайваннарны утарга кертмичә генә сыйлап җибәрәчәкләр.

Моңа кадәр аларны 450 гектар мәйданда кыргый табигатькә якын шартларда асраганнар. Солы, арпа, үлән белән тукланганнар. Ирекккә чыгарылган Шомбыт тыюлыгында да аларга бөтен шартлар тудырылган дип саный белгечләр.

– Беренчедән, якын-тирәдә боланнарның төп дошманнары – бүреләр юк. Икенчедән, мараллар һәм тимгелле боланнар биеклектә яшәргә җайлашкан. Ә биредә диңгез өсте тигезлегеннән – 194 метр. Өченчедән, комлы туфрак булганлыктан, әчелек юк, димәк, бактерияләр дә үрчи алмый. Аннан соң иң якын авыл да дүрт чакрым ераклыкта урнашкан. Бу урыннарны «Татарстан тайгасы» дисәк тә була, чөнки урманнар күп. Шулай ук сулыклар да җитәрлек, – ди Альберт әфәнде.

Кыргый хайваннарны ату тыелган, әмма популяция артса, алар Татарстанның төп аучылык ресурсы булып торачак. Мондый уникаль урын киләчәктә туристларны да күпләп җәлеп итәр, мөгаен. Альберт әфәнде әйтүенчә, бирегә кыргый хайваннарны күрергә теләүчеләр шактый килә икән.

– Бер күреп киткән кеше безгә кабат-кабат килә, – ди ул.

Балык Бистәсе районы башлыгы Илһам Вәлиев тә киләчәктә бу җирләрне туристлык кластеры буларак күрә.

– Без әлеге җирләрне Рус Әшнәгендә төзеләчәк «Балыкчылар авылы» белән тоташтырырга телибез. Киләчәктә биредә туристлык кластеры булачак. Бу бит кешеләрне эш урыны белән дә тәэмин итү дигән сүз. Европада болан аулау өчен лицензия 500 мең сум тора, кулланыла торган итнең 30 проценты – болан ите. Бу яклап та ул финанс ягыннан отышлы булыр, – ди Илһам әфәнде.

Татарстанның экология һәм табигый байлыклар министры урынбасары Фаяз Шакиров әйтүенчә, Россиядә сирәк очрый торган хайваннарны кыргый табигатькә чыгару программасы Экология елы кысаларында башкарыла.

– Бүген Россиядә 3000 баш тимгелле болан һәм марал бар. Киләчәктә табигать әйләнешен тотар өчен аларның санын арттыру максаты куелды, – ди ул.

Зөһрә САДЫЙКОВА.

БУ КЫЗЫКЛЫ!

Урманчы **Илсур Кәримов:**

– Тимгелле болан елга бер һәм бик сирәк очракта гына ике мәртәбә үрчем бирә. Ул яхшы, ышанычлы, иркә ана. Әлеге кыргый хайваннар бик башлы, алар белән сөйләшергә, серләшергә кирәк, шуннан соң гына бер-береңне аңлый башлыйсың. Боланнарга яхшы мөнәсәбәттә булсаң, алар да сиңа начарлык эшләми. Әлеге хайваннарга кешедә була торган сыйфатлар: сизгерлек, тугрылык хас.

АШ БУЛСЫН!

«Карлыгач» торты

Башта бисквит камырын пешерәбез. Өч йомырканың сарысына ярты стакан шикәр комы салып күпертәбез. Ике аш кашыгы көнбагыш мае, өч аш кашыгы каймак салып болгатабыз. Бер, бер ярым стакан онга көпшәкләгеч (разрыхлитель) өстәп, күпертелгән йомырка өстенә салабыз. Өч аш кашыгы кайнар суны әз-әзләп сала-сала болгатабыз. Табага пергамент кәгазе җәеп, камырны бушатабыз. Газ мичендә 15 минут тотып алабыз да өстенә туралган груша, әфлисун, алма кисәкләре сибәбез. Өч йомырка агы һәм шикәр комын миксер белән туглыйбыз да өстенә агызабыз. Туглап бетергәндә әз генә аш серкәсе тамызырга кирәк. 15-20 минутка газ миченә куябыз. Өсте кызаргач, шырпы белән тишкәлибез.

Мәрьям МИҢНЕГОЛОВА,
Азнакай.

БАКЧАЧЫГА

Кырмыскаларга каршы – каен дегете

Үн ел буена бакчадагы «дуслар»ны – кырмыскаларны бетерү өчен мин нинди генә ысуллар кулланмадым: яз җиткән саен, ояларын кайнар су белән пешекләп тә, бор кислотасына шикәр сибеп «сыйлап» та карадым. Алай да бетмәгәч, кибеттән махсус порошок алып кайтып та сипкәләдем. Күптөрле көрәш ысулларын куллануыма карамастан, алар үрчи торды. Боларга каршы тагын ничек көрәшергә, нинди ысуллар кулланырга дип уйланып йөргән көннәрнең берсендә, интернет киңлекләрендә бер шәп ысулга юлыктым. Бактың исә кырмыскалар каен дегете исен яратмыйлар икән! Бүген теплицага кереп барганда бер кырмыска «сәлам биреп», тиз-тиз генә юлымны кисеп үткәч, мин бу ысулны үз тәҗрибәмдә кулланып карарга булдым. Даруханәгә барып, башта каен дегете, аннары көнкүреш товарлары сатыла торган кибеттән поролон алдым да кайтуга эшкә керештем. Башта агачларга тәрәзә-ишекләрне җылыту өчен кулланыла торган поролонны урадым, аны тимерчыбык белән ныгытып куйдым һәм савыт-саба юа торган губка белән каен дегетен һәркайсына сылап чыктым. Каен дегетенең бик үк тәмле булмаган исе, мин сиңа әйтим, бөтен дөньяга таралды, кырмыскаларны гына түгел, үземне дә куалап өйгә кертеп җибәрерлек булды. Хәзер кырмыска «дусларның» реакциясен көтәсе генә калды. Бу ысул минем үземә бик ошады. Иренмәсәгез, сез дә эшләп карагыз. Флакондагы каен дегете нибары 30 сум тора, поролонга 60 сум түләдем. Ничек кенә дисәң дә, үзе арзанлы, үзе экологик яктан чиста ысул.

Венера МӘҖИТОВА,
Башкортстан.

ХУҖАБИКӘГӘ

Сода ярдәмгә килә

✓ Кайнар су тутырган ваннага 100 грамм сода салсагыз, суыгыз йомшарып китәр.
✓ Аягы тирләгән кешегә аяк киеменә сода сибәргә кушалар.
✓ Каһвә хуш исле булсын өчен, аны кайната торган суга бер чеметем сода салыгыз.
✓ Суыткычтан ямьсез исне бетерергә дә сода булыша. Тәлинкәгә сода салып, суыткыч киштәсенә куегыз.
✓ Суга аз гына сода салсагыз, кәбестә һәм фасоль тизрәк пешә.
✓ Черки тешләгән урынга дымлы сода сылагыз.

СӘЛАМӘТЛЕК

Могҗизалы эчемлек

Әлеге эчемлекне өч ай дәвамында эчәргә кирәк. Бер чөгендер, ике кишер, бер алманы кабыгыннан чистартып, сокчыгаргычка салабыз да согын чыгарабыз. Эчемлекне шунда ук эчәргә кирәк. Могҗизалы эчемлек бавыр, бөер, йөрәк, ашказаны асты авыруларын булдырмаска ярдәм итә, иммун системасын яхшырта. Эчәклек эшчәнлеген яхшырта, организмнан агулы матдәләрне чыгара.

АШЫГЫЧ ЯРДӘМ

Аяклары тирли торган кешеләргә гади генә киңәш

Даруханәдән фурацилин дигән дару аласыз. Ике төймә даруны ике литр җылы суда эретәсез. Барлыкка килгән эремәне тазга салып, шуңа аякларны тыгып утырасыз. Һәр көн шулай ун минут утырырга кирәк. Аякларны соңыннан сөлгесез генә киптерәсез.

Аяк киемен дезинфекцияләү өчен шулай ук даруханәдән формалин алыгыз. Тукыма кисәген шуңа манып, аяк киеме эчен сөртәбез дә полиэтилен пакетка салып куябыз. Пакетны бәйләп куясы була. Бер тәүлектән соң аяк киемен пакеттан чыгарып җилләтәсез.

МӘЛЕНӘ – ӘМӘЛЕ

Күн итекләрне кышка сакларга куйганда, формаларын югалтмасын өчен, эчләренә журнал тыгып калдыр.

БЕЛЕП ТОР!

ГӘҮДӘҢ МАТУР БУЛСЫН ДИСӘҢ, ТҮБӘНДӘГЕ КИҢӘШЛӘРНЕ ИСТӘ ТОТ

- Көненә аз-азлап биш-алты тапкыр ашагыз. Иртәнге һәм төшке аш туклыклы, кичке аш җиңелчә булырга тиеш.
- Суны күп эчегез. Олы кеше көненә 1,5-2 литр чиста су эчәргә тиеш. Су организмнан шлакларны һәм агулы матдәләрне чыгара.
- Иртән ач карынга су эчегез. Суга бер телем лимон салсагыз да була.
- Иртәнге ашны калдырмагыз.
- Яшелчә һәм җиләк-җимеш ашагыз. Аларны чи килеш кулланырга тырышыгыз.
- Спорт белән шөгыльләнегез.
- Йокларга өч-дүрт сәгать кала ашагыз.
- Кечкенә тәлинкәдән ашагыз. Психологлар тәлинкәнең зәңгәр төстә булуын да шарт итеп куя. Ул, имештер, ашыйсы килүне баса.
- Йокыгыз туйганчы йоклагыз.
- Күпләр, ябыгучыларның рационында углеводлар булырга тиеш түгел, дигән фикердә тора. Бу – ялгыш фикер. Дөресен әйткәндә, гади углеводлар турында онытырга кирәк. Ә менә катлаулы углеводларны, әйтик, ярмаларны ашарга кирәк.
- Телевизор каршында ашамагыз. Сезнең бөтен игътибар телевизорда булып, күпме ашаганыгызны контрольдә тота алмыйсыз.
- Ризыкны парда пешереп ашагыз.
- Баллы ризыкларны ашауны чикләгез. Алар – фигураның төп дошманнары.
- Яшел чәй эчегез. Ул табигый антиоксидант булып тора.
- Кичке ашны ашаганнан соң, 20 минут урамда йөреп керегез.
- Аксым ашагыз. Ит, балык, күкәй, эремчекне рационыгызга кертегез.
- Ризыкны озаклап чәйнәгез.

ХАТЫН-КЫЗЛАРГА

Яулыкны матур итеп бәйләү серләре

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА әзерләде.

«Балам булачак дип ышанып яшәдем»

Авылдашым Гөлназның биш бала анасы икәнен белгәч, сокланып, танышым өчен сөенеп куйдым. Кияүгә чыккач, ун ел баласы булмады аның.

Эльвира МОЗАФФАР

СИН КӨТ КЕНӘ

Гөлназ белән бер ишегалдында уйнап үстек. Ул бик тыйнак иде. Кич чыкмады, егетләр белән очрашмады. Норлат урта мәктәбен тәмамлагач, кибетче, массаж ясаучы һөнәрләрен үзләштерде. Соңрак Мулла Иле авылы егете Рамил белән танышып, аны армиядән көтеп алып, гаилә корып җибәрделәр. Тик менә бәхетләрен тагын да ныгытырга бала җитми... Ул көннәрне күршем күңелсез төш кебек искә ала.

– Айлар, еллар уза торды, ә балабыз һаман юк. Иремә рәхмәт, ул беркайчан да: «Бала алып кайтмыйсың», – дип бәгырьне телгәләмәде. Табибларга да, кайберәүләр кебек, күрәзәчеләргә дә йөрмәдек, Аллаһы Тәгаләдән сорап, сабыр гына көттек, – ди авылдашым. – Мин әни булачагыма һәрвакыт ышанып яшәдем, өметне өзмәдек. Кайчакта үзем дә гаҗәпләнә идем: бөтен тереклек нәсел калдыра, мин дә бала тарга тиештер бит инде, дия идем. Ниһаять, Аллаһының рәхмәте белән, олы улыбыз Раилне алып кайттык. Көттергән, тансык, тәмле бала булды ул. 11 яшь инде үзенә.

Икенче уллары Ранил тугач та, баланың йөрәгенә операция ясатырга туры килгән. Бүген дә аның белән хастаханә юлын еш таптыйлар. Зарланмыйлар. Хәзер Ранилгә – алты яшь, киләсе елга мәктәпкә җыена.

Ранилдән соң Гөлназ кыз бала таба. Тиздән аңа – биш яшь. Ике елдан соң дүртенче балалары Рәсим дөньяга килә. Бер ел элек, кызлары Гүзәлия туу хөрмәтенә, гаиләдә тагын «бәби чәе» гөрләде.

– Балалар күп булгач, шундый күңелле икән, – ди Гөлназ. – Өйдә гайбәт сүз сөйләнми, яман уйларга вакыт калмый. Балалар үзара тату, бердәм. Бер-берсеннән төрле һөнәрләргә өйрәнеп үсәләр. Берәр эш башласак, булдырсалар, булдырмасалар да, дәррәү җыелышып килеп җитәләр. Булышалар, янәсе. Тормыш иптәшемә, ике як әниемә зур рәхмәт, гел ярдәмләшергә генә торалар.

1 ИЮНЬ – ХАЛЫКАРА БАЛАЛАРНЫ ЯКЛАУ КӨНЕ

ҺӘР БАЛА ҮЗ РИЗЫГЫ БЕЛӘН ТУА

Ун ел әти-әни булырга тилмергән Садыйковлар бер-бер артлы бала алып кайта башлагач, зәһәр телләләр: «Хәерче арттырып бала табалар, дәүләт акча бирә, шуңа кызыгалардыр», – кебегрәк сүзләр дә ишеттергән.

– Кеше минем күңелдәгене аңламый бит. Озак еллар баласыз яшәгәч, Ходай биргән бу могҗизадан ничек баш тартасың?! Аборт ясату – зур гөнаһ. Кеше гомерен өзәргә берәүнең дә хакы юк. Карындагы баланы юк итү турында уй башыма да килмәде. Кеше сөйли торды, мин таба тордым. Әйе, башкаларга булган дәүләт ярдәмен дә алдык: икенче балага ана капиталы акчасын, өченче сабыйга җир кишәрлеге бирделәр. Ул җир тик тора әлегә. Ничек кенә булмасын, һәр сабый үз ризыгы белән туа. Баланы акчага кызыгып алып кайту – мәгънәсезлек. Мөмкин дә түгелдер, – ди Гөлназ.

Күршемнең бәйләмнәрен күреп, тагын бер кат таң калдым. Бәйләүгә осталыгын моңа кадәр белмәгәнмен. Беренче тапкыр кулга йомгак, энә алганда, сигез яшьләр тирәсе иде дип искә ала ул. Ни хикмәт, бәйләргә аны берәү дә өйрәтмәгән. Дәү әнисеннән күреп отып калган.

– Бәйләргә өйрәт дип дәү әниемә ялынсам да, вакыты булмагандыр инде, күрәсең. Иң беренче оекбаш бәйләгәнем истә. Бик авыр булды. Балтыры итәк кебек җәелә дә китә, елый-елый сүтеп, кабат бәйли идем. Ничек кенә булмасын, әнәне ташламадым. Аннары бәйләү үрнәкләрен төрле журналлардан карап өйрәндем. Ә хәзер дөнья рәхәте. Интернет ярдәмгә килә. Балаларыма да киемнәрне бәйләп кидерәм, – ди Гөлназ.

Садыйковлар гаиләсе һәр минутның кадерен белергә өйрәнгән. Һәр мизгелне кызыклы, мәгънәле итәргә тырыша алар. Сабыр төбе – сары алтын, диләр. Түзем булуның әҗере Аллаһы Тәгалә бүләге – балаларына сөенеп яши Гөлназ белән Рамил. Балалары аларның өметләрен акласын, тормышларында терәк булсын иде.

Кара еланнар азды

Кара еланнар котыра башлады дип, май башында халык бер шаулап алган иде. Тукай һәм Зәй районнарында еланнарны күрүчеләр шактый булган. Хәзер менә көннәр җылына башлауга, еланнар тагын активлашкан. Редакциягә дә укучылардан кара еланнарга кагылышлы сораулар еш килә башлады.

«Бездә кара еланнар азды. Алардан ничек сакланырга? Колорадо коңгызын «җиңәргә» өйрәндек, еланнарны шул агу белән куркытып булмыймы? Алар нәрсә белән туклана? Ул бер сәбәпсез кешегә һөҗүм итә аламы? Елан чакса, активлашкан күмер эчәргә ярыймы? Елан нәрсәдән курка (эт, песи, керпе)?» дип, бер-бер артлы сораулар яудырган безгә Буа районыннан Саттаров, Зарипов, Камаловлар.

Кара еланнар уңаеннан биология фәннәре докторы, орнитолог Илгизәр Рәхимовка мөрәҗәгать иттек.

– Колорадо коңгызына каршы агуны еланнарга кулланмыйлар. Гомумән, кара еланны үтерергә ярамый, алар сирәк очрый һәм шунлыктан Кызыл китапка кертелгән. Моны онытмаска кирәк, – ди орнитолог.

Илгизәр Рәхимов әйтүенчә, еланнар беркайчан да үзләре һөҗүмгә ташланмый. Гадәттә, кеше, еланны күреп, үзе аңа таяк белән төртә башлый яки җиләк, гөмбә җыйганда, ялгыш баса. Еланнар үзләренә куркыныч янаганда гына чагалар.

– Алар кеше бакчаларына да ялгышып кына керә. Шуңа да елан күргәнсез икән, сак булырга кирәк. Ул үзе шуышып чыгып китәчәк, – ди галим.

Өстәвенә, дару җитештергәндә, бары тик кара еланның гына агуы кулланыла икән.

– Еланнарның ишетү сәләте бик көчле. Шуңа алар, гадәттә, кешене сизсәләр, үзләре качу ягын карый. Начар күрәләр, әмма телләре белән тиеп, тәмне сизәләр. Песи белән эттән курыкмыйлар. Ә менә керпедән шүрлиләр, –ди орнитолог.

Ана гади кара елан август аенда 17-19 сантиметр озынлыктагы 14ләп бала тудырырга сәләтле. Олы еланнарның озынлыгы 80-90 сантиметрга җитә. Гади кара елан вак кимерүчеләр, кәлтә, бака, ояларын җирдә ясаучы кошларның балалары белән туклана.

КАРА ЕЛАН ЧАКСА

- Авыз эчендә яралар булмаса, яра кырыйларын кысып, тиз арада агуны суырып төкерергә тырышыгыз.
- Кискен хәрәкәтләр ясамагыз.
- Аллергиядән дару һәм мөмкин кадәр күбрәк су эчегез.
- Табибка мөрәҗәгать итегез.
- Яралы урынга жгут салырга ярамый, алкогольле эчемлекләр куллану да тыела.
- Укучыларыбызның соравына килгәндә, елан чакканнан соң, активлашкан күмер эчәргә ярый. Шулай да ул гына авыруның хәлен җиңеләйтә дип әйтеп булмый.

Үз йорты белән яшәгән авыл агасының ихатасына ничә машина сыя дип уйлыйсыз? Күп дигәндә, өч-дүрттән артмый торгандыр. Хәер, төләүле машина утарларының да урыны чутсыз түгел анысы. Ә менә Азнакай районы Тымытык авылында яшәүче Нәфис Миннегалиевнең берүзенә 600 (!) машинасы бар. Аларның һәркайсысы 43 тапкыр кечерәйтелгән булса да, әлеге «машина утары» шактый зур урын таләп итә коллекционердан. Аның 40 ел дәвамында җыелган тупланмасын күргәч, ирексездән, машина индустриясенең үсешен өйрәнергә менә кая барырга кирәк икән дисең. Һәр машинасының, әлбәттә, ничек алынуыннан башлап үз тарихы бар. Үзе кубрәк йөк машиналарын ярата төшә икән.

БЕРҮЗЕНӘ 600 МАШИНА

Расиха ФӘИЗОВА

Иң беренче булып Нәфиснең күзе легендар «полуторка»га – сугышка кадәр һәм сугыш елларында Горький автозаводында чыккан «ГАЗ-АА» (1932 елдан башлап чыгарылган) машинасына төшә. 1974 еллар була бу. «Полуторка»ның аягы җиңел була. Аңа үзебезнең «КамАЗ», бераздан Мәскәүнең «ЗИЛ»ы килеп кушыла.

– Әти дә, бөтен туганнар да шоферлар минем. Үзем дә кечкенәдән шофер булырга хыялланган идем, – ди гомер буе колхозда бухгалтер, баш бухгалтер булып эшләп, әле шушы арада гына 60ын түгәрәкләп лаеклы ялга чыккан Нәфис Миннегалиев.– Элек өч сум да илле тиен тора иде алар. 70 сумга эшләгән кешегә анысы да кыйммәт тоела иде. Ни дисәң дә, бер тиенгә бер кап шырпы ала торган чаклар бит әле ул.

Чыннан да, хәзер генә тулып ята алар, шулай да кайбер модельләрне җиде, сигез меңгә дә кулга төшерә алмаска мөмкин икән әле. Ә элегрәк коллекцион машиналарны табу, гомумән, җиңел булмый. Әмма ниятенә кергәч, әмәлен табалар. Теләсә кайсы шәһәрнең Ленин урамында яшәүчегә (ялгышлык була алмый, чөнки мондый урам бөтен җирдә дә бар) җайлап кына хат язып, теләгән модельне почта аша кайтарту җаен карыйлар.

– Шулай да сезне иң сөендергән машина кайсысы булды – беренче 50 машинамы, йөзенчесеме? – дип кызыксынам коллекционердан.

Кайчандыр әтисе Гаптелгалинең вафатына кадәр эшләгән «ГАЗик» булып чыкты ул (ә ул бик иртә – 50 яшендә үк бакыйлыкка күчкән). Ни кызганыч, аз эшләнелә икән алар. Алай да Чаллы егетләре аша табып, ике машинага алыштырып алган. Янгын сүндерү машиналарын табуы да кыен, ди. Тупланмада фәнни-тикшеренү институтларында ясалып, күпләп җитештерүгә чыкмаган машиналар да бар.

Һәр экспонатны үзенчә шәрехли бара Нәфис Миннегалиев.

– Менә монысында сугыш вакытында офицерлар йөргән, ә менә бу – «Место встречи изменить нельзя» фильмында Шарапов йөргән машина. Менә бу «ЗИЛ-157»не дә шактый эзләргә туры килде...

Сукырның теләгәне ике күз дигәндәй, монда башка – машина чире: соңгы вакытта «ГАЗ-52»не таба алмый интегүе икән. Оныклары булган кешегә мондый тупланманы исән-имин тоту да җиңел түгелдер дип куям.

– «Балалар һөҗүме» дигәннән, моннан элек үзебез санаториягә киткәч, өйдә әни калды. Ул авылда бездән аерым яши. Аулак өйгә әнинең тугыз оныгы җыелган. Рәхәтләнеп сүткәннәр машиналарны. Кайткач, балаларга сүз әйтүен әйтмәдем, әмма эчтән генә әрнедем инде. Үземнең хәзер ике оныгым бар. Әдиләгә – сигез, Айзиләгә – ике яшь. Курчак белән уйный белмиләр – машина булсын аларга да,– ди коллекционер.

АВЫРУНЫ ҖИҢӘРГӘ БУЛЫШКАН ХИКМӘТ

Кирәк икән, булам танкист, ял иткәндә – фалерист. Мәгълүм җырны нигәдер әнә шулай «бозасы» иттем. Гәрчә армиядә булмаса да, Нәфис Миннегалиев монда да кыек атып туры тидерә. Машиналар тупланмасына өстәп җыйган сугыш техникасы – 100дән артык танк өстенә дүрт меңгә якын значогы да бар бит әле аның. Значоклар җыю белән мавыгу нәкъ менә фалеристика (орден, медальләр, күкрәк билгеләре, значоклар) дип атала да. Монысы мәктәп яшеннән үк килгән шөгыле Нәфиснең. Значоклары темаларга бүленеп, тәртип белән альбомга урнаштырылган. Машиналар, һөнәри бәйрәмнәр, шәхесләр (Ленин значоклары), шәһәрләр, һөнәрләр... Хәтта ки Туган көн дигән значокка кадәр бар.

– Менә болары генераллар, маршалларныкы – каян алгандыр, белмим. Берәү бүләк итте, – ди ул, бүреккә беркетелә торган кокардыны күрсәтеп.

Ә монда алар җитәрлек. Армиянекеннән, министрлыклар, ведомстволарның аерымлык билгеләреннән кала машина «маңгаена» чәпи торганнары да җитәрлек.

– Элек бөтен җирдә значок саталар иде. 10-15 тиен иде ул. Значок тагып йөрү гадәте дә бар иде. 1991 еллардан соң значокны сатуда күргәнем дә юк. Казанда Ленин музеена кергән идем, шаккатып чыктым. Пролетариат юлбашчысының башы төшерелгән бер значок та күрмәдем,– дип гаҗәпләнә ул, үзенең балачак мавыгуының «модасы» чыгуына бераз көрсенеп. Әмма аңа карап кына значок җыючылар бетми. Юк-юкта алыш-биреш ясарга шалтыратучылар булгалый икән. Элек йә тартмага, йә вымпелга кадап җыйган значокларны барларга да тәҗел сәбәп кирәк булган, күрәсең.

Иренең сүзен хатыны Тәзкирә ханым (пенсиягә кадәр сельпо рәисе булып эшләгән) күтәреп ала.

- ✓ Коллекционерлар башкаларга караганда депрессиягә, стресска сирәк бирешә.
- ✓ Дөнья халкының 20 проценты ни дә булса җыя.
- ✓ Россия коллекционерларының һәр бишенчесе – нумизмат.
- ✓ Коллекционерлар үзләренең чордашларыннан озаграк яши.

– 2010 елда яман шеш авыруыннан бер-бер артлы өч авыр операция уздырды Нәфис. Табиблар: «50гә 50», – диделәр. Шул чагында: «Әйдәгез, балалар, әтиегезгә бер шөгыль табыгыз», – дидем. Авыруны онытыра торган шөгыль, хәрәкәт кирәк иде. Шул вакытта махсус альбомнар алып, бөтен тупланмасын тәртипкә салды. Шуның белән генә җиңдек авыруны...

АКЧАЛАРЫ ЯНЧЫКТА ДА, БАНКТА ДА ТҮГЕЛ

Бухгалтер кеше коллекционер булып та, нумизматика (сугылган акчалар), бонистика (кулланыштан чыккан акчалар, кәгазь акчалар җыю) белән кызыксынмаса, гаҗәп тоелыр иде. Бу юнәлешне дә бертигез алып бара Нәфис Гаптелгали улы. Сүзебез шушы җиргә килеп җиткәч, танышымның икенче сулышы ачылгандай була. Чөнки гомер буе акча белән эш иткән кеше буларак, судагы балык кебек ул монда. Биредә дә барысы да эзгә салынган: борынгы акчалар, юкка чыккан илләрнең акчалары (ГДР, Чехословакия, СССР һ.б.), сәер акчалар (әйтик, бер ягында 10 мең булып, икенче ягында «0»ләрне өстәргә онытып, берлек булып кына калган акча), АКШ президентларына багышланган серия һ.б.

– Бүгенге көндә миндә 266 илнең акчасы бар, ә менә 22 илнең йә тиен акчасы, йә кәгазь акчасы юк. Күпме сорап та, әлегә кәгазь бер евро таба алганым юк, нигәдер банкларга бирмиләр икән шуны – ди ул, – хәзер, бер карaганда, проблема юк, чит илгә күп йөриләр. Туганнар, дуслар минем кызыксынуны белгәч, ярдәм итәргә генә тора. СССР вакытында үзем дә Румыния, Венгриядә булдым. Татарстанның яшьләр төркемендә (5 егет, 31 кыз) җитәкчесе булып Болгариягә бардым. Бөтен районнардан бар иде яшьләр. Без анда ичмасам шорты киярге өйрәнеп кайттык, – дип, яшьлек елларын искә ала Нәфис Миннегалиев.

Менә шулай, авылда мал асрап, каралты-кура нығытып яшәгән кешенең 600ләп машинасы булуга да, Зимбабве миллиардлары белән эш итүенә дә аптырыйсы юк.

PS. Бу көннәрдә Нәфис Миннегалиев тупланмасының бер өлеше Азнакайның Төбәкне өйрәнү музеенда күрсәтелә.

Фарсель Зыятдинов:

«Тын алырга да вакыт юк»

Фарсель абый Зыятдиновны һәркем үзенчә белә. Бакчачы да ул, агроном, педагог, икътисадчы, галим, язучы, шагыйрь, журналист, тәрҗемәче, геодезист, топограф та. «Бу өлкәләр барысы да күңелемә бертигез якын», – ди үзе. Бүген – 1 июньдә, 80 яшьлек юбилеен каршылаганда да, Фарсель абыйның тик торганы юк. «ШК» журналистлары аны гомер бәйрәме белән котлап кайтты.

Эльвира МОЗАФФАР

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

ЯЗМЫШТАН УЗМЫШ ЮК

Фарсель абый көн саен очрашуларда: әле радиода, телевидениедә, әле шигырьләрен видеотасмага яздырта… Быел республиканың тугыз районында булып кайткан.

– Укытучылар, китапханәчеләр белән башта иҗатым турында сөйләшәбез, шигырьләремне укыйм, аннары бакчачылык буенча сораулар яудыра башлыйлар, – ди Фарсель абый.

Менә инде тугыз ел ул яшьлектәге дусты Венера апа белән гомер итә. Безне дә ул каршы алды. Фарсель абыйның кайтуын көткән арада, Венера апа белән яшьлек елларын искә алдык.

– Фарсельне 15 яшемнән беләм. Актанышта очрашканыбызны хәтерлим. Мин көянтә-чиләк белән су алып кайтып барганда, артымнан килде дә: «Апасы, кайчаннан бирле артыңнан кайтам, миңа су эчермисеңмени?» – диде. Ул чакта бер-беребезнең исемен дә сорамадык. Аннары 1963 елда Минзәләдән Казанга самолет белән очканда таныштык. Ул миңа гел ярдәм итә иде. Без аның белән чын дуслар булдык. Юлларыбыз гына аерылды. Тик, эш буенча, сирәк булса да күрешә идек, – дип сөйли Венера апа.

Фарсель абыйның тормыш иптәше – барыбызга да таныш шагыйрә Фирая апа Зыятдинова вафатыннан соң бер ел узгач, алар кабат очрашалар. Бер ел телефоннан сөйләшеп торалар. Венера апа да ялгызы гына калган, кызы үз гаиләсе белән яши. Фарсель абый Венера апаны үзенә күченеп килергә үгетли. «Язмыштан узмыш юк, күрәсең. Безгә олыгайган көндә бергә яшәргә язган булгандыр», – ди Венера апа.

Ул да түгел, юбилярыбыз үзе дә кайтып җитте.

– Венера инвалид улым Айвазны сигез ел карарга ярдәм итте. Былтыр 45 яшендә улым фаҗигале төстә вафат булды. Яшь чагында аны явыз ниятле егетләр каты гына кыйнаганнар иде. Хәрби хезмәттән бөтенләй имгәнеп кайтты. Татар булганы өчен кыйнаганнар. 1991 еллар, милли көрәш кызган чак бит. Кайткач, озак кына хастаханәдә дә дәваланды, тик башына зыян килгән булып чыкты. Кайвакыт безгә сиздерми генә өйдән чыгып китә торган гадәте бар иде. Былтыр 18 апрельдә чыгып киткән җиреннән кайтмады. 4 майда гына үле гәүдәсен Каменка тукталышы тирәсендәге агачлыктан таптылар. Билеты булмагач, аны автобустан төшереп калдырганнар, күрәсең. Ул җиргә ятып йоклаган да башка уянмаган. Бу вакыйганы Венера да, мин дә бик авыр кичердек. Ярый киңәшләшергә, терәк булырга янымда кеше бар, – ди Фарсель абый.

«ЕЛАГАЧ, ҖИҢЕЛРӘК БУЛЫП КИТӘ»

– Фарсель абый, бала югалту ачысын беренче генә кичермисез. Кызыгыз Алсу да вакытсыз бакыйлыкка күчкән иде дип беләм.

– Әйе шул. 1964 елда Фирая белән өйләнешеп яши башлагач, кызыбыз туды. Аңа ике яшь булгач, сырхауханәгә прививка ясатырга бардык. Шприцларны кайната торганнар иде ул чакта, шәфкать туташы укол ясаганда балага инфекция керткән. Кызыбызның хәле яхшырсын дип, яшәргә авылга да кайтардык. Тик рәтләнә генә алмады. Курчак кебек Алсуыбызны югалтуны бик авыр кичердек. Зиратка баргач, Фирая: «Әйдә, каберен казып карыйк әле, исәндер ул», – дип, туфракны тырный-тырный елаганы истә.

Фарсель Зыятдинов 1937 елның 1 июнендә Актаныш районы Качкын авылында туа. Өч уку йортын тәмамлый, икътисад фәннәре докторы, академик. «Татар энциклопедиясе»н әзерләүдә актив катнаша. Өч дистәгә якын шигырь, проза һәм фәнни китаплар авторы. Әдәбият, мәдәният, фән өлкәләрендәге хезмәтләре өчен, 1992 елда «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исемгә лаек булган.

– Фирая апа үзе дә арабыздан кинәт китеп барды…

– Фирая үзен сакламады. Аңарда диабет иде. Дөрес, табиблар да вакытында дәваламадылар. Каты авырый башлагач, яман шеш дип уйладылар. Тикшеренүләр үтәргә онкология диспансерына юлладылар. Ә Фираяның ашказаны җәрәхәте ачылып, кан киткән булып чыкты. Шул рәвешле көтмәгәндә гүр иясе булды. Аның белән 42 ел яшәдек. Ул минем зур ярдәмчем иде. Шигырьләремне, проза әсәрләремне кәгазьгә басучы, укып, фикерләрен әйтүче дә ул булды. Айваз өчен гел борчылды. Үләсен сизгәндәй: «Мин булмасам, бу баланы кем карар?» – дия иде. Шөкер, ике улыбыз исән-сау. Айдар белән Айнур, оныклар – юанычыбыз. Ике яшьлек оныкчыгымның биегәнен күрсәм дә, кәеф күтәрелә.

Хәтер йомгагын сүткәндә, әңгәмәдәшем яшьләрен тыя алмый.

– Елагач, җиңелрәк булып китә. Тешеңне кысып булса да түзәсең. Үзеңдә көч табарга тырышасың. Элек язган шигырьләремне укыгач, барысы да искә төшеп, шундый авыр булып китә. 1964 елдан бирле көн саен көндәлек алып барам, – ди Фарсель абый.

Хис-кичерешләр, уйлануларны сыйдырган бу куен дәфтәрләре белән китап киштәсе тулган. Көндәлек һава торышын да ул шунда язып бара.

– Күзәтүләрдән чыгып әйтә алам: май аенда быелгы кебек озакка сузылган салкынның 50 ел булганы юк иде. Дөрес, өченче ел 23 майда кар яуды. Июнь аен да эссе булыр дип әйтеп булмый. Яңгырлар көтелә. Ә менә июль гадәттәгедән дә җылырак булыр дип фаразлыйм. Сентябрь бик матур килер, мөгаен. Шуңа да кыяр белән помидорны ачык грунтка 15 июньдә утыртсагыз да өлгерә әле, – дип киңәшләрен бирергә дә онытмады Фарсель абый.

Әңгәмәбез үзеннән-үзе бакчачылык темасына күчте.

«ФАРСЕЛЬ» ДИГӘН АЛМАГАЧ

– Бакчачылык белән кызыксынуыгыз ничек башланды?

– Әти сугыштан 1947 елда гына кайтты. Миңа ул чакта ун яшь иде. Әти кайткан төшкә кыяр үстергәнемне хәтерлим. Авылда беренче кыяр үстерүче мин булдым. Пучы авылыннан орлыгын алып кайткан идем. Зур булып үссен дип, сулар сиптем. Әтине иң зурысы белән сыйладым. Кыярның зурайгач саргайганын, ә кечерәкләре тәмлерәк икәнен уйламаганмындыр инде. Әтинең рәхмәт әйткәне истә. Әле күрше малайлар ул кыярны урлап чыгалар иде. Аптырагач, берничә кыярга эчне йомшарта торган дару салдым, дип ялганларга туры килде. Аның каравы бакчага керми башладылар.

– 1964 елда телевидениедә бакчачылык турында тапшырулар эфирга чыга башлаган.

– Элек бит бакчада яшелчә, җиләк-җимеш үстерүчеләр бик сирәк иде. Минзәлә районындагы бер урыс авылыннан килеп, әчи башлаган тозлаган кыяр, помидор саталар, шуны авыл халкы чират торып ала. Шуны үзебез үстерә алмыйбызмы инде, дип ачу килә башлады. Журналист Кыям Янгуловка, бакчачылыкка багышланган тапшыру ачыйк, дип тәкъдим иттем. Халыкны котыртыйк, янәсе. Шуннан бирле тынгылык биргәннәре юк. Трамвайда, автобуста барганда да киңәш сораучылар табыла.

– Үз бакчагызда әллә нинди сирәк очрый торган үсемлекләр бардыр, Фарсель абый?

– Минем бакчам алты сотый. Элек бит дүрт сотыйдан артык бирмиләр иде. Әмма, гаиләсен туендырырлык дәрәҗәдә яшелчә, җиләк-җимеш утыртыр өчен, кешегә ун сотый җир кирәк, дип саныйм. Без Голландиядән кайткан тюльпаннар, Төркия чәчәкләре үстерәбез. Моның белән Венера шөгыльләнә. Яман шештән файдалы зелпе агачы да үстергәнем булды. Хәзер алтын тамыр дигән үсемлекне яратып кулланабыз. Гомумән, күп кенә дару үләннәрен бакчамда үстереп, үзем сынап карыйм. Тугызлап алмагач бар. Гадәттә, алманы, капчыклап, кешеләргә өләшәбез. Кура җиләген бик яратам. Аны кышка да катырып куябыз.

– Үзегезнең берәр төр үсемлек уйлап чыгарганыгыз булмадымы соң?

– Бар. «Фарсель» алмагачы уйлап чыгарган идем. Тик ул корыды. Фәннәр академиясе хезмәткәрләре, ялгау өчен, берничә ботагын кисеп тә киткәннәр иде. Бәлки бу төр тагын барлыкка килер әле.

Фарсель абый: «80 яшьлек юбилеемны эшләп каршылыйм, тын алырга да вакыт юк», – ди. Көне иртәнге зарядкадан башлана икән. Элегрәк кышын дусты, курсташы шагыйрь Равил Фәйзуллин белән чаңгыда йөри, җәен бакчасында өчәр сәгать мунча керә, рәхәтләнеп чабына, Иделдә коена. Бергә җыелышканда, туган-тумачалар 70ләп була ди. Күңеле тулганда, иҗатка бирелә. Әле менә «Ата күңеле – балада» дигән хикәяләр, повестьлар җыентыгы табадан төшәргә тора. Якташы, классташы, Татарстанның Беренче Президенты Минтимер Шәймиев тә котлавыннан калдырмый. Бу юлы, ураза вакытына туры килгәнгә, туган көн кичәсен кичектерергә туры килгән. Хәер, туган ягы Актанышта бәйрәмне узган атнада ук гөрләткәннәр инде. Без дә газетабыз белән даими элемтәдә торган Фарсель абый Зыятдиновка иң изге теләкләребезне җиткерәбез.

СӘЛАМӘТЛЕК

ГАСТРИТ

Гастрит – бүгенге көндә иң еш очрый торган авыруларның берсе. Аның килеп чыгу сәбәпләре, билгеләре, кисәтү чаралары турында Казан шәһәренең 7нче хастаханәсендә гастроэнтерология бүлеге җитәкчесе Диләрә Исхакова белән сөйләштек.

Эльвира МОЗАФФАР

